**72 нче номерлы «Антошка» балаларның танып-белү-сөйләм үсешен өстенлекле гамәлгә ашыручы гомумүстерешле балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе**

Раслыйм:

**Заведующий**

**МБДОУ «Детский сад №72 «Антошка»**

Педагогик берләшмә утырышында
Каралды һәм кабул ителеде
“__29_” _август__ 2024 ел
№ 1 беркетмә

# 2нче номерлы икенче кечкенәләр (3-4 яшь) төркеменең 2024 - 2025 нче уку елына эш программасы.

**Төзүче:** Галиева Л.З.

Яр Чаллы
2024 ел

## Эчтәлек

**1. Максатчан бүлек..........................................................................................................3**
1.1.Программаны тормышка ашыру максаты ...............................................................3
1.2. 3-4 яшьлек балаларның яшь үзенчәлекләре.......................................................6
1.3.Төркемнең эшчәнлегенең юнәлеше.......................................................................8
1.4. Программаны үзләштерү өчен ният ителгән нәтиҗәләр......................................9
**2. Эчтәлек бүлек.............................................................................................................10**
2.1. Белем өлкәләре буенча комплекслы – тематик планлаштыру............................10
2.2. Гаилә белән үзара бәйләнеш...................................................................................25
2.3.Җәмгыять белән хезмәттәшлек.................................................................................29
**3.Оештыру бүлеге..............................................................................................................30**
3.1. Материаль – техник тулыландыру………………………………………………...30
3.2. Программа һәм методика белән тәэмин итү.........................................................31
3.3. Үстерешле предметлы тирәлек………..…………………………………………..38
3.4. Көндәлек режим..........................................................................................................44
3.5. Белем бирүэшчәнлеге челтәре...............................................................................47
3.6. Чыныктыру чаралары.................................................................................................48
3.7. Традицион вакыйгалар, бәйрәмнәр, чаралар үзенчәлекләре.............................50

**Кушымта**

**1. Максатчан бүлек.**

**1.1 Программаны тормышка ашыру максаты.**

Бу программа “Мәктәпкәчә төп гомуми белем бирү программасы структурасына, Федераль дәүләт таләпләре”нә нигезләнеп, ФОП программасына,балалар бакчасының еллык эш планына таянып төзелде.

**Эш программасының максаты:**

- Балаларның яшь һәм шәхси үзенчәлекләрен исәпкә алып мәктәпкәчә яшьтәге балаларны физик, интеллектуаль, шәхси сыйфатларын үстерү.

**Эш программасының бурычлары:**

1. Балаларның аң һәм физик үсешенең табигый процессына уен, аралашу, танып-белү, хезмәт, хәрәкәт, матур әдәбият уку, музыка- иҗат, ясау эшчәнлеге.
2. Белем өлкәләрен үзләштергәндә психологик һәм педагогик яктан ярдәм итү.
3. Режим моментларында, ирекле белем бирү , мөстәкыйль, ата-аналар белән эш вакытында зурлар-кечкенәләр бердәм (партнерлык) эшчәнлеген оештыру

Программа куйган максатларга ирешүдә түбәндәгеләр беренче әһәмияткә ия:

- балаларны аралашучан, игелекле, кызыксынучан, инициативалы, мөстәкыйльлеккә һәм иҗатка омтылучан итеп үстерү максатыннан чыгып, төркемнәрдә кешелеклелек һәм мәрхәмәтлелек атмосферасы тудыру;
- балалар эшчәнлегенең төрле төрләрен киң куллану; укыту һәм тәрбия процессының нәтиҗәлелеген күтәрү максатыннан аларны интегральләштерү;
- тәрбия һәм белем бирү процессын иҗади оештыру;
- балаларның мөмкин булганча төрле эшчәнлекләрен файдалану; белем бирү процессын нәтиҗәлерәк итү максатында аларны берләштерү (интегральләштерү);
- мәктәпкәчә тәрбия һәм белем бирү оешмалары һәм гаилә шартларында бала тәрбиясенә якын килүгә юнәлеш бирү;
- гаиләнең балалар бакчасы төркемнәре һәм, гомумән, мәктәпкәчә оешма тормышында катнашуын тәэмин итү;
- балалар бакчасы һәм башлангыч мәктәп эшендә мәктәпкәчә яшьтәге балага кирәгеннән артык акыл һәм физик эш йөкләмәү максатыннан дәвамчанлыкны саклау;
- региональ якын килүне гамәлгә ашыру.

**Эш программасының төп фикере -** укыту, тәрбияләү, сәламәтлеген саклау белән бергә баланың шәхесен үстерү.

**Эш программасының күрсәткече:**

*Белем өлкәләрен интеграцияләү нигезендә тулы педагогик процессны төзү;

*Балаларның  яшь һәм шәхси  үзенчәлекләрен исәпкә алып төп юнәлешләр – физик, социаль-шәхси, танып белү-сөйләм, нәфис-нәфасәти  үсеш юнәлешләре буенча төрлеяклап үстерү;
*Балаларның  иҗади сәләтен ачу, сәләтлеләрне табу, шәхси үстерү өчен яңа технологияләр куллану;
*Балаларның мөмкинчелегеннән, кызыксынучанлыгыннан, сорауларыннан чыгып төрле төр эшчәнлекләрне үстерү;
*Эчтәлекле аралашуга, сөйләшүгә төзелгән шәхси һәм төркем белән эшчәнлекләр оештыру;
*Балага  эшчәнлектә үзен күрсәтү, эш эчтәлеген, эш төрләрен, эштә иптәш сайлау хокукы бирү.

**Эш программасы түбәндәге норматив документлар буенча яраклаштырылган:**

*Федераль дәрәҗәдә:*

- Федераль закон  «Рәсәй Федерациясендә белем алу» от29.12.2012 г. N 273-ФЗ
- Закон РТ «Белемалу турында»;
- Методическими рекомендациями Минобрнауки «О разработке основной    общеобразовательной программы дошкольного образования» от 21 октября 2010 года, № 03-248.
- Санитарно-эпидемиологическими требованиями к устройству, содержанию и организации режима дошкольных образовательных учреждений (СанПиН 2.4.1.3049-13);

*Региональ дәрәҗәдә:*

- Приказ Министерства образования и науки РТ от 17.11.2010 СЭД-26-01-21-164
- «О разработке основной общеобразовательной программы дошкольного образования»;

*Җирле  дәрәҗәдә:*

- Устав муниципального бюджетного  дошкольного образовательного учреждения города Набережные Челны «Детский сад общеразвивающего вида с приоритетным осуществлением деятельности по позновательно-речевому направлению развития детей № 72 «Антошка» утвержден постановлением Руководителя ИК от 29.03.2012 года № 1579.
- Приказ МБДОУ «Детский сад № 72 «Антошка»от 17.10.2013года № 297а«О разработке примерной основной общеобразовательной программы дошкольного образования МБДОУ «Детский сад № 72 «Антошка».
- План работы  МБДОУ «Детский сад № 72 «Антошка» на 2016-2017 учебный год.
- Основная общеобразовательная программа МБДОУ «Детский сад № 72 «Антошка» . Приказ № 278а  от 29 августа 2018года.

Эш программасын тормышка ашыру срогы- 1 ел (2024-2025уку елы)

**№ 2  төркемнең комплектлыгы**

| №гр | Яшь | Барлыгы | Малайлар | Кызлар | Норма буенча тулыш | Чынбарлыктагы тулыш |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 2 | 3-4 | 18 | 10 | 8 | 28 | 18 |

**№ 2төркемнең социальпаспорты**

| №п/п | Баланың фамилиясе, исеме | Тулы\ тулы түгел гаилә | Гаиләдә ничә бала |
|---|---|---|---|
| 1. | Абдрахманова Алиса Альбертовна | тулы түгел | 2 |
| 2. | Газизов Алан Динарович | тулы | 2 |
| 3. | Гайнутдинова Айсылу Ильнуровна | тулы | 2 |
| 4. | Гимранов Даян Русланович | тулы | 1 |
| 5. | Даянова Диляра Рифатовна | тулы | 1 |
| 6. | Зайнуллин Риналь Ранисович | тулы | 2 |
| 7. | Исхаков Султан Булатович | тулы | 1 |
| 8. | Каюмова Марьям Ильназовна | тулы түгел | 2 |
| 9. | Саитгараев Марат Равилевич | тулы | 2 |
| 10. | Саматов Ринас Ринатович | тулы | 2 |
| 11. | Сафина Ясмина Расимовна | тулы | 2 |
| 12. | Стець Георгий Романович | тулы | 1 |
| 13. | Фазлыева Ксения Ильдаровна | тулы | 1 |
| 14. | Хайруллин Арсен Ренатович | тулы | 3 |
| 15. | Шавалиева Амелия Азатовна | тулы | 1 |
| 16. | Шамсутдинов Тамерлан | тулы | 2 |
| 17. | Шангараева Ясмина Маратовна | тулы | 2 |
| 18. | Яхин Ранель Эдуардович | тулы | 1 |

**1.2. 3-4 яшьлек балаларның яшь үзенчәлекләре.**

2 нче “Көнбагышкай” төркеме балаларының яшь үзенчәлекләре.

Бала үсешендә мәктәпкәчә яшь чоры күп төрле һәм динамикалы булуы белән аерылып тора. Әлеге чор дәвамында төрле юнәлешләр буенча сизелерлек үзгәрешләр барлыкка килә. Уен, рәсем, төзү кебек эшчәнлек төрләре камилләшә. Безнең күз алдында 3—4 ел дәвамында балаларның игътибарры, хәтере, фикерләве, күзаллавы, сөйләме көчле үсеш ала. Гади җөмләләр катлаулылары белән алышына һәм кызыклы кечкенә хикәяләргә әверелә. Бу яшьтә баланың дуслары барлыкка килә башлый, ул һәм зурлар белән теләп аралаша, үз тәртибен көйли. Дөнья турында күзаллавы киңәя һәм «нигә?», «ни өчен?» сораулары җавап таләп итә. Мәктәпкәчә яшь чорының башы 3 яшьтәге кискен үзгәреш белән туры килә. Иртә яшьтә үсеш һәм тәрбия дөрес оештырылган булса, баланың 3—4 яшьтә буе 90—100 смга җитә, гәүдә авырлыгы якынча 13—16 кг була. Аның җитезлеге арта, тизрәк йөгерә, яхшырак сикерә, ыргыткан тупны ике кулы белән тотып ала. Әле 2 яшьтә ул бу хәрәкәтләрнең берсен дә эшли белми иде! 3—4 яшьтә балалар физик яктан көчлерәк, мөстәкыйльрәк. Физик тәрбия акыл тәрбиясе белән бәйләнештә алып барыла.

Бу яшьтә акыл, эстетик, әхлак, физик үсеш югары темп ала. Мәктәпкәчә яшьтәге бала әйләнә-тирә дөньяны танып белә, күзәткән вакыйгаларны, күренешләрне аңларга тырыша. Дөрес оештырылган педагогик процесс нәтиҗәсендә балалар төрле төшенчәләрне үзләштерәләр, нәтиҗәләр чыгаралар, гомумиләштерәләр. Балаларның кызыксынучанлыгы, яхшы хәтере аңа күп информация тупларга ярдәм итә. Кызыксынучанлык баланы эзләнү эшчәнлегенә (Н.Н.Поддьяков), зурларга сораулар белән мөрәҗәгать итәргә стимуллаштыра. Сораулар характеры буенча баланың үсеш дәрәҗәсен билгеләргә була. 3—4 яшьлек баланың аралашуы гаилә белән генә чикләнми. Зурлар бала өчен гаилә әгъзасы гына түгел, ә билгеле иҗтимагый функция үтәүче булып та тора. Баланың шундый ук функция үтәргә теләве аның реаль мөмкинлекләре белән каршылыкка очрый. Әлеге каршылык» мәктәпкәчә яшьтә әйдәүче эшчәнлек — уен аша чишелә.

Уенның төп үзенчәлеге, аның шартлы рәвештә булуында. Кече мәктәпкәчә яшьтәге бала уенының төп эчтәлеген уенчыклар һәм предметны алмаштыра торган җиһазлар тәшкил итә. Бу яшьтә балаларның уены озак вакытка сузылмый. Кече мәктәпкәчә яшьтәге балалар уенда берике роль һәм гади сю-жетлар белән чикләнәләр. Кагыйдәле уеннар әле формалаша гына башлый.

3-4 яшьлек балаларның әшчәнлеге катлаулана һәм төрлеләнә: алар уку һәм хезмәт биремнәрен уеннар аера башлыйлар. Уен һәм шөгыль нәтиҗәсендә психик процесслар (хәтер, фикерләү, игътибар, күзаллау) үсеш ала, балаларның яңа ихтыяҗлары һәм мәнфәгатьләре барлыкка килә.

Информатив, катлаулы һәм күләмле күрсәткеч булып акыл үсеше тора. Киң мәгънәдә акыл үсеше төп танып белү про-цессы үсеше буларак аңлатыла. Тар мәгънәдә — акыл сәләте үсеше. Акыл сәләте үсеше баланың әйләнә-тирәдә ориентирлашу ысулларын гомумиләштерүне күз алдында тота.

3-4 яшьлек балалар үсешендә сәнгать эшчәнлеге мөһим урын алып тора. Әлеге эшчәнлек баланың предмет турындагы күзаллауларына бәйле. Бу яшьтә күзаллаулар формалаша гына башлый. График образлар ярлы. Кайбер балаларның рәсемнәрендә детальләр төшеп кала, ә икенчеләре киресенчә, җентекләп ясый. Балалар рәсемнәрдә төрле төсләр куллана башлый. Кул моторикасын үстерү өчен әвәләү, бармаклар гимнастикасы зур әһәмияткә ия. Кече мәктәпкәчә яшьтәге балалар зурлар җитәкчелегендә гади предметлар әвәләргә сәләтле. Кисеп ябыштыруның (аппликация) кабул итү үсешенә уңай йогынты ясавы билгеле. Бу яшьтә кисеп ябыштыруның иң гади төрләрен башкаралар.

Кече мәктәпкәчә яшьтә балаларның төзү эшчәнлеге, үрнәк буенча һәм уйлап чыгарылган катлаулы булмаган төзелешләр белән чикләнә.

Әлеге яшьтә аерым эшчәнлекләр үсеш ала. Балалар башлангыч эталоннарны (кабул итүнең индивидуаль берәмлекләре) кулланудан сенсор эталоннарга (кабул итүнең эшкәртелгән чаралары) күчәләр. Кече мәктәпкәчә яшь ахырына балалар предметларның һәм төсләрнең биштән алып җиде төренә кадәр аералар, предметларны зурлыгы буенча дифференциациялиләр, балалар бакчасының төркем бүлмәсе, белем бирү процессын оештырганада, бөтен балалар бакчасы бинасы пространствосында ориентирлашалар.

Хәтер һәм игътибар үсеш ала. Зурлар үтенече буенча балалар 3-4 сүз һәм 5-6 предмет исемен хәтерләрендә калдыралар. Кече мәктәпкәчә яшь ахрына алар яраткан әсәрләрдән өзекләрне истә калдырырга сәләтле. Күрсәтмә-хәрәкәт фикерләве үсеше дәвам итә. Шуның белән беррәттән, кайбер очракларда, теләгән нәтиҗәләрне исәпкә алып, мак-сатчан үрнәк нигезендә ситуация үзгәрә. Мәктәпкәчә яшьтәге балалар предметлар арасындагы кайбер яшерен бәйләнешне билгеләргә сәләтле. Кече мәктәпкәчә яшьтә күзаллау үсеш ала һәм ул бигрәк тә уенда чагылыш таба.

Балалар арасындагы үзара мөнәсәбәт нормалар һәм кагыйдәләр белән билгеләнә. Максатчан тәэсир итү нәтиҗәсендә, алар үзләренең һәм башка балаларның эшләрен бәяләү өчен ни-гез булган, чагыштырмача зур күләмдә нормаларны үзләштерә алалар. Балалар арасындагы үзара мөнәсәбәт бигрәк тә уем эшчәнлегендә ачык чагыла. Шулай ук бу яшьтә сайлауга корылган үзара мөнәсәбәт тә күзәтелә. Уенчык сайлауга бәйле конфликтлар килеп чыга. Төркемдә баланың иптәшләре арасында тоткан урыны тәрбияче фикере белән билгеләнә.

Кече мәктәпкәчә яшьтә чагыштырмача гади генә ситуациядә тәртип һәм мотивның бер-берсенә буйсынуы күзәтелә. Тәртип белән аңлы рәвештә идарә итүгә әле нигез генә салына, күп очракта баланың тәртибе ситуатив характерда. Шуның белән

берръттън, сүзле күрсәтмәләр ярдәмендә баланың үз теләгән үзе чикләвен күрергә була. Балалар үз мөмкинлекләрен бәяли башлыйлар, ләкин тәрбияче бәяләмәсенә ориентирлашалар.

### 1.3. Төркемнең өстәнлекле юнәлеш эшчәнлеге.

2 нче "Көнбагышкай" төркеме ФОП программасы буенча эшли. Шушы программадан чыгып төркемдә белем эшчәнлегенең атналык тематикасы төзелде:

| **Тема** | **Вакыт** |
|---|---|
| Мәктәп – белем йорты | 02.09-04.09 |
| Исәнме, балалар бакчасы | 07.09- 11.09 |
| Көз байлыклары | 14.09-18.09 |
| Алтын көз | 21.09- 25.09 |
| Алтын көз | 28.09- 30.09 |
| Авылга әбигә кунакка | 01.10- 9.10 |
| Мониторинг | 12.10-16.10 |
| Минем сәламәтлек | 19.10- 23.10 |
| Мин һәм минем гаилә | 26.10-30.10 |
| Мин яши торган өй | 02.11 - 06.11 |
| Минем дуслар | 09.11- 13.11 |
| Кеше хезмәте өчен кирәкле җиһазлар | 16.11-20.11 |
| Үзеңне сакла | 23.11-30.11 |
| Нәрсә нәрсәдән һәм ни өчен? | 01.12-04.12 |
| Менә салкыннар килде һәм кыш җитте | 07.12-11.12 |
| Яңа ел якынлаша | 14.12 -18.12 |
| Яңа ел | 21.12-25.12 |
| Яңа ел | 28.12-31.12 |
| Кыш | 09.01-31.01 |
| Ватанны саклаучылар көне | 01.02 -19.02 |
| 8 Март | 20.02-28.02 |
| 8 Март | 01.03-12.03 |

| | |
|---|---|
| Халык мәдәнияте һәм традицияләре белән танышу | 13.03-31.03 |
| Яз! | 01.04-23.04 |
| Җиңү көне | 24.05-07.05 |
| Җәй | 08.05-31.05 |

ФОП таләпләренә туры китереп оештырылган **белем бирү өлкәләре** түбәндәгечә:

| Оештырылган белем бирү өлкәләре | Саны |
|---|---|
| Танып белү үсеше. Төзү  һәм тәҗрибә эшчәнлеге. ФЭМП һәм әйләнә – тирә белән танышу | 4 |
| Сөйләм эшчәнлеге (матур әдәбият белән танышу) | 1 |
| Иҗади – эстетик үсеш. Сәнгать үсеше. Рәсем, ябыштыру. Җыр | 0,5 /0,5<br>2 |
| Физик үсеш (Физик культура, сәламәтлек) | 3 |
| Социаль– шәхсиүсеш (Хезмәт һәм куркынычсызлык, социальләштерү) интеграция эчендә | |
| Барлыгы: | 10 |

**1.4.Программаны үзләштерү өчен ният ителгән нәтиҗәләр.**

Россиянең төп бердәм мәктәпкәчә белем бирү программасының ФДББСка яраклашуы түбәндәгеләрдә күренә:
 - балачакның үзенчәлеге;
- кешелекнең гомуми үсешендә мәктәпкәчә чорның уникаль булуы;
- өлкәннәр һәм балаларның гуманлы аралашуы;
- баланың шәхесен хөрмәт итү;

- балаларның спецификасын исәпкә алып, белем бирү процессын уен, танып белү, эзләнү, иҗади активлык формасында тормышка ашыру.
Программаны үзләштерү өчен ният ителгән нәтиҗәләр:балаларның белем алу сыйфатын күтәрү; тәрбияләнүче балаларның танып белү, сөйләм үстерү, социаль- коммуникатив, нәфис-нәфасәти һәм физик үсеше сыйфатын күтәрү; МБМББда тәрбияләнүчеләрнең сәламәтләндерү нәтиҗәлелеген күтәрү, педагогларның укыту-методик комплектлар буенча эшләү ысулларын һәм алымнарын өйрәнүен тәэмин итү; балаларның ике телдә аралашулары өчен шартлар тудыру; туган гаиләгә, төбәккә, Ватанга, әйләнә-тирә мохиткә, төрле милләт вәкилләренә хөрмәт тәрбияләү; балалар халкыбызның мәдәнияты һәм гореф-гадәтләре белән кызыксына һәм аларны аера белергә өйрәтүне балаларда сәламәт тормыш рәвешенә, үз-үзләренең сәламәтлегенә җаваплылык хисе тәрбияләү; мәктәпкәчә һәм башлангыч белем бирүдә дәвамчанлык; балаларның физик һәм психик сәламәтлеген саклау һәм ныгыту; балаларга хокук белемнәрен бирү, патриотизм, туган төбәккә мәхәббәт тәрбияләү; кеше хокукларын хөрмәтләү; психолог ярдәме белән балаларга белем бирү эшчәнлегендә туган кимчелекләр өстендә эшләүне камилләштерү; гаиләләр белән элемтәләрне ныгыту.
Уртанчылар төркеме балаларыүзенең туган ягы, туган шәһәре, үзе һәм үзенең гаиләсе турында, табигатькә карата уңай караш тәрбияләнергә һәм әйләнә-тирә мохитта үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен белергә; зурлар ярдәменнән башка танып белү, күзәтүчәнлек һәм экспериментлар белән кызыксынырга;4 – 5 яшьлек балалар үсемлекләр һәм хайваннар тормышы турында белеп, аларга ярдәм итә белергә тиешләр.Транспортта, өйдә, урамда үз-үзен тоту кагыйдәләрен дөрес куллана белү.

## 2. Эчтәлек бүлеге.

### 2.1. Белем өлкәләре буенча комплеклы - тематик план

**“ФИЗИК ҮСЕШ”** ***БЕЛЕМ БИРҮ ӨЛКӘСЕ.***

***СӘЛАМӘТЛЕК.***

«Сәламәтлек» белем бирү эшчәнлеге эчтәлеге балаларның сәламәтлеген саклау, аларда сәламәтлек культурасы нигезләрен формалаштыру максатларын тормышка ашыруга юнәлдерелә һәм белем бирү бурычларын билгели.

Балаларның физик һәм психик сәламәтлекләрен ныгыту буенча эшне; оешма төрен һәм тибын, булган шартларны, төркем тулылыгын, балаларның сәламәтлек һәм үсеш үзенчәлекләрен, шулай ук төбәктәге климатик һәм ел фасыллары үзенчәлекләрен исәпкә алып, бала организмын чыныктыру эшен дәвам итү.

Шәхси гигиена процесслары турындагы күзаллауларын баету. Гигиена нормалары һәм кагыйдәләрен аңлы һәм мөстәкыйль рәвештә үтәүләренә ирешү.

Гади һәм чиста киенү, киемнәрне тәртипләп төрү, бүлмәдә чиста аяк киемендә йөрү күнекмәләрен үстерү.

Ашаганчы һәм ашагач, пычрангач, туалеттан соң кулларын мөстәкыйль рәвештә юарга, тешләрен чистартырга,

ашаганнан соң авызны чайкарга, йоклар алдыннан аякларны юарга гадәтләндерү.

Пөхтә ашау күнекмәләрен камилләштерү: ризыкны азлап кына алу, тавышсыз гына ашау, бик кайнар ризык ашамау, коймау, савыт-сабаны дөрес файдалану.

Милли ризыклар һәм эчемлекләр (умач, татарча азу, казам пылавы, кара җимеш һәм өрекле чәй, хуш исле чәй һ. б.) белән таныштыру.

Бала организмы өчен кирәк булган витаминнар турында күзаллау булдыру. Ризык кабул итү режимын үтәү, җиләк-җимеш, яшелчә, балык һәм сөт ризыкларын (кайнаган сөт, кефир, корт), ит һәм башка файдалы ашамлыкларны куллануга ихтыяҗ тәрбияләү.

«Сәламәтлек» һәм «авыру» төшенчәләре, халык медицинасының кайбер чаралары белән таныштыру. Бәрелгәндә, киселгәндә үз-үзеңә һәм башка балаларга элементар ярдәм күрсәтү, үз сәламәтлегең турында кайгырту күнекмәләре формалаштыру.

***Физик үсеш.***

«Физик үсеш» белем бирү эшчәнлеге эчтәлеге балаларда физик культурага кызыксыну һәм аңлы караш, гар-монияле физик үсеш формалаштыру максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.Балаларда хәрәкәт активлыгына ихтыяҗ формалаштыру. Яшьтәшләре белән зур булмаган төркемнәрдә, үзләре белеп, татар халык уеннарын оештыруда мөстәкыйльлекләрен үстерү. Кагыйдәләрне мөстәкыйль рәвештә үтәргә өйрәтү.Хәрәкәтләнү тәҗрибәсен баету.Хәрәкәтле уеннарда балаларның иҗади сәләтләрен (уен вариантлары, катнаш хәрәкәтләр уйлап чыгару) үстерү.

***“Танып – белү үсеше” белем өлкәсе.***

Танып – белү үсеше баланың мәнфәгатьләре, кызыксынучанлыгы һәм танып – белү гамәлләре, аны формалашуын; хыялы һәм иҗади активлыгы үсешен; үзе, башка кешеләр, әйләнә – тирәдәге объектларның үзлекләре һәм үзара бәйләнешләре, туган җир һәм Туган ил турындагы беренчел күзаллаулары, халкыбызның социомәдәни кыйммәтләре, Ватаныбызның традицияләре һәм бәйрәмнәре, кешеләрнең уртак һәм гомуми йорты буларак Җир планетасы, аның табигатенең үзенчәлекләре, дөньядагы илләрнең һәм халыкларның күптөрлелеге турындагы күзаллаулары формалашуын күз алдында тота.

***Элементар математик төшенчәләр формалаштыру.***

Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның белемнәренә характеристика биргәндә, без белем һәм осталыкларның ике категория-сен аерып күрсәтәбез: беренчесен балалар үз тәҗрибәсе яисә тәрбия чаралары аша алса, икенчесен — балаларга өлкәннәр бирә.

Шуңа күрә балаларның өйрәтүен оештырганда тирә-юньне танып белгәндә балалар нәрсәләрне үзләренең булган тәҗрибәләренә таянып, ә нәрсәне аларга оештырылган өйрәтү процессында бирергә кирәклеген ачык һәм төгәл итеп күз алдына китерергә кирәк:. Белем бирү эчтәлегендә табигать күренешләре» предметлар» кешеләр» аларның мөнәсәбәтләре турындагы белемнәр төп урын алып торырга тиеш. Занятиеләрне һәм мөстәкыйль эшчәнлекне оештырганда балаларга гади һәм аңлаешлы итеп закончалыкларны» күренешләр арасындагы бәйләнешләрне күрсәтергә» белемнәр системасын билгеле бер эзлеклелектә, гадидән катлаулыга таба бирергә кирәк. Икенче кечкеләр тәркемендә аеруча игътибарны сенсор тәрбиягә бирү сорала. Мәктәпкәчә белемнәр системасы мәктәп белемнәре системасыннан аерыла һәм аерылырга тиеш. Белемнәрне систематизацияләү төрле тирәнлек һәм гомумиләштерү дәрәҗәсендә була ала: эмпирик дәрәҗәдә, бу вакытта белемнәрнең төп эчтәлеге күзаллау формасында бирелә (элек кабул ителгән предметлар (күренешләр) образында) һәм югары — теоретик дәрәҗәдә» бу очракта белемнәр төшенчәләр формасында кабул ителә» ә бәйләнешләр тирән закончалыклар буларак характерлана.

Үзенең структурасы буенча белемнәр системасы төрле була ала, балаларның акыл үсешенә күбрәк дәрәҗәдә иерархик принцип буенча тезелгән белемнәр йогынты ясый. Андый белемнәр системасы үзәк башлангыч төшенчәнең булуы белән характерлана, бу төшенчәдән башкалары барлыкка килә. Уңышлы акыл үсешен булдыру максатыннан чыгып» фәкать шундый белемнәр системасын кулланырга тәкъдим итәбез.

Системалы үзләштерелгән белемнәр мәктәпкәчә яшьтәге балаларның тирә-юньне анализлауга булган мөнәсәбәтен үзгәртә һәм аларда яшерен бәйләнешләрне» мөнәсәбәтләрне эзләүгә этәргеч ясый. Предметларның» күренешләрнең тышкы үзлекләрен тикшереп карау эчке бәйләнешләрне һәм үзлекләрне танып белү максаты белән эшләнә. Балалар бар нәрсәне предмет булу кузлегеннән чыгып анализлый башлыйлар.

***Комплекслы – тематик план***

| Ай | Атна | Эшчәнлек темасы | Бурычлар |
|---|---|---|---|
| сентябрь | I | Адаптация вакыты | Балаларны ирекле белем эшчәнлегенә әзерләү. Үткәннәрне искә төшерү. |
| | II | **Тема.** Шар, куб. | Балаларда контраст зурлыктагы предметлар турында күзаллау формалаштыру, зур һәм кечкенә сүзләрен куллану; шар һәм кубны аера, атый |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | белүләрен ныгыту.2. Балаларның күрсәтмә-образлы фикерләвен, сенсор сәләтләрен, әйләнә-тирәдәге предметларны танып белүгә кызыксынуларын үстерү.3. Әйләнә-тирәгә яхшы мөнәсәбәт тәрбияләү. |
| | III | **Тема.** Зур-кечкенә. | Төрле төстәге предметларны чагыштыру, күбрәк – азрак төшенчәләрен дөрес куллану, тәүлек өлешләрен ныгыту. |
| октябрь | I | **Тема.** Бер, күп, аз. | Саны буенча предмет төркемнәрен аера белүләрен ныгыту, алар арасында бәйләнеш урнаштырганда бер, күп, аз сүзләрен куллану. Төркемдәге барлык предметларга һәм аның аерым өлешләренә генә хас булган гомуми билгеләрне табу. Кызыл, сары, яшел кебек төсләрнең исемнәрен кабатлау. |
| | II | **Тема.** Предметларның бертөрле һәм төрле-төрле билгеләре.<br>Төркемнән бер предметны аеру. | 1. Аерым предметлардан төркем төзергә, характерлы билгеләре буенча предметны төркемнән аерырга өйрәтү; предметларның саны буенча бәйләнеш урнаштырганда «бер», «күп», «аз», «берәү дә юк» сүзләрен куллану.<br>2. Балаларның игътибарын, зиһенгә алуларын һәм табигатьнең матурлыгын тоемлауларын, тәрбияче соравына аңлаешлы итеп җавап бирә белүләрен үстерү.<br>3. Сорауларга җавап бирү теләге, табигатькә мәхәббәт тәрбияләү. |
| | III | **Тема**. Предметлар төркеме төзү, төркемнән бер предметны аеру. | 1. Аерым предметлардан төркем төзергә, һәм төркемнән бер предметны аерып алырга, «ничә» соравына җавап бирергә өйрәтүне дәвам итү һәм предмет җыелмаларын «бер», «күп», «берәү дә юк» сүзләре белән билгеләү.<br>2. Балаларның игътибарын, зиһенгә алуларын, образлы фикерләвен, кызыксынучанлыгын үстерү.<br>3. Табигатькә сакчыл караш һәм хайваннарга уңай мөнәсәбәт тәрбияләү. |
| | IV | Түгәрәк, квадрат. | 1. Түгәрәк белән квадрат турында күзаллаулар формалаштыру; кул хәрәкәтен тоемлау юлы белән фигураны тикшерү; аерым предметлардан төркем төзи һәм төркемнән предметларны аера белүләрен камилләштерү; бирелгән төркемгә керә торган барлык предметларга һәм аның аерым өлешләре өчен генә хас булган билгеләрне табу, төркемне төркемчәләргә бүлү; күп, бер, берешәр, берәү дә юк сүзләрен сөйләмдә активлаштыру. Уң һәм сул кулларны аеруда күнектерү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | 2. Балаларның күрсәтмә-образлы фикерләвен, кызыксынучаялыкларын, сенсор сәләтен һәм кул моторикасын үстерү.<br>3. Үзара ярдәм, яшьтәшләре коллективында эшли белү, төгәллек кебек сыйфатлар тәрбияләү. |
| ноябрь | I | Балаларның яшь үзенчәлекләрен һәм программа материалын ничек үзләштерүләрен исәпкә алып эшне иректе планлаштыру | Белемнәрне баету, тикшерү. |
| | II | **Тема**. Бер, күп, берәү дә юк. | 1. Балаларны алдан әзерләп куелган шартларда бер һәм күп предметлар табарга өйрәтү, предметларның санын «Бер паровоз, күп вагоннар», «Паровоз берәү, ә вагоннар күп» сүзләре белән белдерү. Түгәрәкне аерырга, атарга һәм капшамлы хәрәкәтләр белән тикшерергә, үлчәме (размеры) буенча түгәрәкләрне чагыштырырга өйрәтүне дәвам итү. Уң һәм сул кулларны аеруда күнектерү.2. Балаларның зиһенгә алуларын, игътибарын, күрсәтмә-образлы фикерләвен, кызыксынучанлыкларын, сенсор сәләтен һәм кул моторикасын, өлешләрдән бөтен төзи белүләрен үстерү. |
| | III | **Тема.** Озын-кыска, озынрак-кыскарак. | 1. Берсе янына икенчесен куеп карау ысулы белән ике предметны озынлыгы буенча чагыштырырга, нәтиҗәләрне озын-кыска, озынрак-кыскарак сүзләре белән белдерергә өйрәтү Предметның охшаш һәм охшаш булмаган якларын аерып күрсәтә белергә, предметларның санын «бер», «күп», «берешәр», «берәү дә юк» сүзләре белән белдерергә өйрәтүне дәвам итү.2. Балаларның зиһенгә алуларын, игътибарын, коммуникатив эшчәнлеген үстерү.<br>3. Әдәплелек, (исәнләшү, ярдәм өчен рәхмәт әйтү), башкаларга ярдәм итәргә теләге, музыкага эмоциональ җавап бирә белүләрен тәрбияләү. |
| | IV | “**Тема.** Бер-күп.<br>ләү. | 1. Балаларны алдан әзерләп куелган шартларда бер һәм күп предметлар табарга өйрәтү, предметларның санын «ә», «һәм» текркәгечләре кулланып |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | ” | җөмләләр ярдәмендә белдерү. Түгәрәк һәм квадратны формасы һәм төсе буенча аера, атый белүләрен ныгыту; кул хәрәкәтен тоемлау юлы белән фигураны тикшерүдә күнектерү. Пространство бәйләнешләрен «төбендә» (тәрәзә төбендә) бәйлек сүзе белән белдерү.<br>2. Балаларның игътибарын, тактиль тоемлауларын, зиһенгә алуларын, коммуникатив эшчәнлекләрен үстерү.<br>3. Коллективта эшләү, башкаларга ярдәм итү теләге, музыкага эмоциональ җавап бирүчәнлек тәрбия |
| декабрь | I | **Тема.** Күп, никадәр-шулкадәр, бертигез. | 1. Бер әйберне икенчесе өстенә куеп карау ысулы белән предметларның ике төркемен чагыштырырга, күп, никадәр-шулкадәр, бертигез сүзләренең мәгънәсен аңларга өйрәтү. Балаларны үз гәүдәләрендә дөрес ориентирлашуда, уң һәм сул кулларны аеруда күнектерү. Ике предметның озынлыгын бер әйберне икенчесе өстенә һәм бер әйберне икенчесе яны-на куеп карау ысулы белән чагыштырырга өйрәтүне дәвам итү, нәтиҗәне озын-кыска, озынрак-кыскарак сүзләре белән белдерү.2. Балаларның фикерләвен, тактиль тоемлый, җырның характерын тоеп, бию хәрәкәтләре башкара белүләрен үстерү.<br>3. Балаларда бер-берсенә яхшы мөнәсәбәт, ярдәм итү теләге, үз-узеңне тота белү күнекмәләре тәрбияләү. |
| | II | “**Тема.** Күп, бертигез, никадәр-шулкадәр. | 1. Берсе өстенә икенчесен кую ысулы белән ике тигез предметлар төркемен чагыштырырга өйрәтүне дәвам итү, чагыш-тыру нәтиҗәсен күп, бертигез, никадәр-шулкадәр сүзләре белән билгеләү. Берсе өстенә икенчесен кую һәм берсе янына икенчесен кую ысулы белән ике предметны озынлыгы буенча чагыштыру күнекмәсен камилләштерү, чагыштыру нәтиҗәсен озын-кыска, озынрак-кыскарак, озынлыгы буенча бертигез сүзләре белән билгеләү.<br>2. Балаларның зиһенгә алуларын, кул чукларын һәм бармак мускулларын, үз фикерләрен җөмлә рәвешендә белдерә белүләрен үстерү.<br>3. Балаларның тыңлый һәм иптәшләрен ишетә белүләрен тәрбияләү |
| | III | **Тема.** Күп, бертигез, никадәр-шулкадәр. | 1. Берсе өстенә икенчесен кую ысулы белән ике тигез предметлар төркемен чагыштырырга өйрәтүне дәвам итү, сөйләмдә күп, бертигез, никадәр- |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | шулкадәр сүзләрен активлаштыру. Балаларны төрле анализаторлар ярдәмендә күплекләрне зиһенгә алуда күнектерү. Озын-кыска, озынрак-кыскарак, озынлыгы буенча бертигез сүзләре кулланып, берсе өстенә икенчесен кую һәм берсе янына икенчесен кую ысулы белән ике предметны озынлыгы буенча чагыштыру осталыгы камилләштерү.<br>2. Балаларның тәрбияче артыннан зур булмаган җөмләлә-рен кабатлый, үз фикерләрен җөмлә рәвешендә белдерә белүләрен, фикерләүләрен һәм зиһенгә алуларын үстерү.<br>3. Балаларның иптәшләрен ишетә, тынлый, тәрбияче бир-гән күрсәтмәләр буенча эшли белүләрен тәрбияләү. |
| | IV | **Тема.** Киң-тар, киңрәк-таррак. | 1. Берсе өстенә икенчесен кую һәм берсе янына икенчесен кую ысулы белән киңлеге буенча контраст булган ике предметны чагыштырырга өйрәтү, чагыштыру нәтиҗәсен киң-тар, киңрәк-таррак сүзләре белән билгеләү. Тигез ике төркем предметларын берсе өстенә икенчесен кую ысулы белән чагыш-тырырга өйрәтүне дәвам итү. Уң һәм сул кулларны аеруда күнектерү.<br>2. Фикерләүне, сенсор сәләтне» тактик тоемлауны, чагыштыру сәләтен, хәрәкәтләрне шигырь эчтәлегенә туры китереп башкаруны үстерү.<br>3. Балаларда занятиедә үз-үзеңне тәртипле тоту, ярдәмчеллек, мәрхәмәтлелек кебек сыйфатлар тәрбияләү. |
| гыйнвар | I | Программа материалының үзләштерелешенә һәм икенче кечеләр төркеменең үзенчәлекләренә карап эшне ирекле планлаштыру. | Алда алган белемнәрне ныгыту, балаларның зиһеннәрен үстерү.. |
| | II | Программа материалының үзләштерелешенә һәм икенче кечеләр төркеменең үзенчәлекләренә карап эшне ирекле планлаштыру. | Алда алган белемнәрне ныгыту, балаларның зиһеннәрен үстерү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | III | **Тема.** Өчпочмак. | . Өчпочмак белән таныштыру: фигураны танырга һәм атарга өйрәтү, хәрәкәтне тою ысулы белән тикшереп карау. Ике тигез группа предметларын берсе өстенә икенчесен куеш карау ысулы белән чагыштыру осталыгын камилләштерү, чагыштыру нәтиҗәләрен күп, бертигез, никадәр-шулкадәр сүзләре белән билгеләү. Квадрат, түгәрәк сүзләрен дөрес атау һәм аера белү осталыгын формалаштыру. Ике предметны киңлеге буенча чагыштыруны ныгыту, киң-тар, киңрәк-таррак сүзләрен кулланырга өйрәтү.<br>2. Күрсәтмә-образлы фикерләүне, тикшерү сәләтен, нәрсә киңрәк, нәрсә таррак икәнен аеруны, балаларның тоемлау тәҗрибәсен үстерү.<br>3. Үзара дуслыкны, әйләнә-тирәнең матурлыгын күрү, коллективта уйнау сәләте тәрбияләү. |
| | IV | **Тема.** Күп, бертигез, никадәр-шулкадәр. | 1. Ике бертигез группа предметларын берсе янына икенчесен куеп карау юлы белән чагыштырырга, чагыштыру нәтиҗәләрен күп, бертигез, никадәр-шулкадәр сүзләре белән белдерергә өйрәтү. Ике предметны киңлеге буенча чагыштыру осталыгын ныгыту, нәрсәнең киңрәк, нәрсәнең таррак икәнен аерырга, киң-тар, киңрәк-таррак, киңлеге буенча бертигез сүзләрен кулланырга өйрәтүне дәвам итү. |
| февраль | I | **Тема.** Күп, бертигез, никадәр-шулкадәр. | 1. Ике бертигез төркем предметларын берсе янына икенчесен куеп карау юлы белән чагыштырырга һәм чагыштыру нәтиҗәләрен күп, бертигез, никадәр-шулкадәр сүзләре белән билгеләргә өйрәтүне дәвам итү. Геометрик фигураларны (түгәрәк, квадрат, өчпочмак) аера һәм атый белүләрен камилләштерү. Үзеннән чыгып пространство юнәлешләрен билгеләүдә күнектерү һәм аларны өстә-аста сүзләре белән билгеләү. Тар-киң, таррак-киңрәк сүзләрен сөйләмдә кулла-нуны ныгыту. |
| | II | **Тема.** Биек-тәбәнәк, биегрәк-тәбәнәгрәк. | 1. Биеклеге буенча ике предметны чагыштыру алымнары белән таныштыру, биек-тәбәнәк, биегрәк-тәбәнәгрәк сүзләрен аңларга өйрәтү. Үзеңнән чыгып яссылык юнәлешләрен билгеләүдә күнектерү. Ике тигез группа предметларын берсе ягы-на икенчесен куеп карау ысулы белән чагыштыру осталыгын һәм күпләп, бертигез, никадәр-шулкадәр сүзләрен куллануны камилләштерү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | 2. Фикерләүне, сенсор сәләтләрне, тактиль тоемлауны, чагыштыру осталыгын, кул хәрәкәтләрен матур итеп башкара, алу осталыгын үстерү.<br>3. Балаларда ярдәмчелелек, дустанә мөнәсәбәт, яхшы бәя бирә алуны, занятиедә үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен саклау осталыгын тәрбияләү. |
| | III | Программа материалының үзләштерелешенә һәм икенче кечеләр төркеменең үзенчәлекләренә карап эшне иректе планлаштыру. | Алда алган белемнәрне ныгыту, балаларның зиһеннәрен үстерү. |
| | IV | **Тема.** Күп -аз, никадәр-шулкадәр. | 1. Берсен икенчесенә кую ысулы белән ике тигез булмаган предметлар группасын чагыштырырга өйрәтү, чагыштыру нәтиҗәләрен күп-аз, никадәр-шулкадәр сүзләре белән белдерү. Үз гәүдәләре якларында (уң, сул) ориентирлашуда күнектерү. Биеклеге буенча ике контраст предметларны чагыштыра белүне дәвам итү, чагыштыру нәтиҗәләрен биек-тәбәнәк, биегрәк-тәбәнәгрәк сүзләре белән белдерү. |
| март | I | **Тема.** Күп-аз, никадәр-шулкадәр. | 1. Берсе өстенә икенчесен һәм берсе янына икенчесен куеп карау ысуллары белән ике тигез булмаган предметлар группасын чагыштырырга өйрәтүне дәвам итү, чагыштыру нәтиҗәсең күп-аз, никадәр-шулкадәр, бертигез сүзләре белән билгеләү. Өскә-аска, көн-төн, иртә-кич сүзләрен куллануны ныгыту.<br>2. Балаларның фикерләвен, диалогик осталыкларын, предметларн **Тема.** Күп-аз, никадәр-шулкадәр. |
| | II | **Тема.** Күбрәк-азрак, никадәр-шулкадәр. | . Предметларның тигез һәм тигез булмаган ике төркемен чагыштыру осталыгын камилләштерү, бертигез, никадәр-шулкадәр, күбрәк-азрак чагыштырмаларын сөйләмдә куллану. Ике предметны озынлыгы һәм биеклеге буенча чагыштыру ысулларын ныгыту, чагыштыру нәтиҗәләрен тиешле сүзләр белән белдерү. Түгәрәк, квадрат, өчпочмакны аера һәм атый белүдә күнектерү. 2. Предметларның үзлекләрен аера, тәрбияче сорауларына җавап бирә, әйләнә-тирә табигать матурлыгын тоемлый белүләрен, кызыксынучанлыкларын үстерү.. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | III | Программа материалының үзләштерелешенә һәм икенче кечеләр төркеменең үзенчәлекләренә карап эшне ирекле планлаштыру. | Алда алган белемнәрне ныгыту, балаларның зиһеннәрен үстерү. |
| | IV | “Бармаклар белән капшап исәпләү. Калын, нечкәрәк, бик нечкә” | Балаларны предметларны капшап санарга, аларның исәбен билгеләргә өйрәтү;предметларның калынлыкларына карап, аларны чагыштыру. |
| апрель | I | **Тема.** Өстенә, астына, эченә. | 1. Өстенә, астына, эченә бәйлек сүзләре кулланып предметларның пространствода урнашуын билгеләргә өйрәтү. Сөйләмдә бертигез, никадәр-шулкадәр, күбрәк-азрак чагыштырмаларын кулланып предметларның тигез һәм тигез булмаган ике төркемен чагыштыра белүләрен ныгыту. Ике предметны зурлыгы буенча чагыштыруда күнектерү, чагыштыру нәтиҗәләрен озын-кыска, озынрак-кыскарак, бертөрле (бертигез) озынлыкта сүзләре белән белдерү. |
| | II | **Тема.** Тоюю органнары ярдәмендә күплекләрне кабул итү. | 1. Үрнәк буенча (санамыйча һәм санын әйтмичә) предмет һәм авазлар санын кабул итәргә өйрәтү. Тиз-акрын сүзләренең мәгънәсен анлату. Бер предметны икенчесе өстенә кую, берсе янына икенчесен куеп карау ысуллары ярдәмендә ике бертигез һәм тигез булмаган предмет группаларын чагыштыруны, никадәр-шулкадәр, күбрәк-азрак, бертигез сүзләрен куллануны ныгыту. Ике предметны зурлык буенча чагыштыруда күнектерү, чагыштыру нәтиҗәләрен зур-кечкенә сүзләре белән билгеләү.<br>2. Зиһенгә алуны, фантазияне, игътибарны, хыялый фикерләүне, ритм тоемлавын, хәрәкәтләрнең ритмлылыгын һәм төгәллеген үстерү. |
| | III | “**Тема.** Тоюю органнары ярдәмендә күплекләрне кабул итү. | 1. Балаларны ничә уенчык торса (1-3 чикләрендә), шул кадәр хәрәкәт ясарга өйрәтү. Капма-каршы тәүлек өлешләрндә ориентирлаша белү осталыгын ныгыту: көн-төн, кич-иртә. Табигать күренешләре (тәүлек өлешләре) турындагы белемнәрне ачыклау, тирәнәйтү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | 2. Аналитик-синтетик эшчәнлеккә булган нигезләрне, зиһенгә алу, игътибарлылык, фонематик ишетү сәләтен, вакыт тоемлавын, төгәл һәм төрле итеп үз фикереңне һәм хисләреңне чагылдыра алу осталыгын, туган телнең тәэсирлегән, телнең сәнгатьле чараларын үзләштерүне үстерү. |
| | IV | **Тема.** Алда-артта, өстә-аста, сулда-уңда. | 1. Предметның зурлыгын аерып алырга һәм күрсәтергә, бирелгән билгесе буенча төркемнән бер, күп предметларны аерырга өйрәтү. Баланы үзенә карата пространство юнәлешләрен аера белүдә һәм аларны алда-артта, өстә-аста, сулда-уңда сүзләре белән билгеләүдә күнектерү. Аерым предметлардан төркем төзү һәм шул төркемнән бер предметны аерып алу осталыгын камилләштерү. |
| май | I | **Тема.** Геометрик фигуралар. | 1. Бирелгән сыйфатлары буенча предметны төркемнән аерып алу осталыгы формалаштыру. Геометрик фигураларны төсе һәм зурлыгы буенча төркемләү.<br>2. Продуктив аналитик-синтетик фикерләү эшчәнлеген, музыкаль кабул итүчәнлекне, игътибарны, кызыксынучан-лыкны, зирәклекне, реакциянең тизлелеген үстерү.<br>3. Уңай нәтиҗәгә ирешү теләге, үзара килешеп эшләү осталыгы, занятиегә кызыксыну тәрбияләү. |
| | II | “Предметларны биеклекләренә карап чагыштыру” | Төрле биеклектәге элементларны тәртип буенча бер рәткә тезү, кайсы предметны кая куярга кирәклеген хәтердә калдырырга күнектерү; авазларны санау күнегүләрен башкару. |
| | III | **Тема.** Геометрик фигуралардан (түгәрәк, квадрат, өчпочмак) рәсемнәр төзү. | . Балаларны билгеле бер рәсем төзү өчен әзер геометрик фигураларны (түгәрәк, квадрат, өчпочмак) танырга, атарга, сайларга, тезәргә һәм ябыштырырга өйрәтүне дәвам итү. Күплек, зурлык, форма, төс, яссылык, вакыт турындагы белемнәрне ныгыту.<br>2. Күрсәтмә-образлы фикерләүне, кабул итүне, игътибарны, күз алдына китерүне, сөйләм этикеты осталыгы, яссылыкта, вакытта ориентирлашуны, моториканы һәм бармакларның вак хәрәкәтләрен, кызыксынучанлыкны, зирәклекне үстерү.<br>3. Кошларга һәм бөҗәкләргә, әйләнә-тирәгә яхшы мөнәсәбәт, геометрик |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | фигураларны ябыштырганда пөхтәлек, матурлык хисен тою, занятиегә кызыксыну тәрбияләү. |
| | IV | Программа материалын үзләштерүне һәм конкрет яшь төркеменең үзенчәлекләрен исәпкә алып эшне иректле планлаштыру. | Алда алган белемнәрне ныгыту, балаларның зиһеннәрен үстерү. |

***"СӨЙЛӘМ ҮСЕШЕ" БЕЛЕМ БИРҮ ӨЛКӘСЕ.***

Сөйләм үсеше аралашу һәм мәдәният чарасы буларак сөйләмгә ия булуны; актив сүзлекне баетуны; бәйләнешле, грамматик яктан дөрес диалогик һәм монологик сөйләмне; сөйләм иҗаты үсешен; сөйләмнең аваз һәм интонация культурасы, фонематик ишетү сәләте үсешен; китап культурасы, балалар әдәбияты белән танышуны, балалар әдәбиятының төрле жанрлары текстларын ишетеп аңлауны; укырга – язарга өйрәтүнең алшарты буларак авазлы аналитик – синтетик активлык формалашуны үз эченә ала.

***СӨЙЛӘМ ТЕЛЕН ҮСТЕРҮ.***

Өлкәннәр һәм балалар белән иректле аралашуны үстерү, тирә – юньдәгеләр белән үзара тәэсир итешүнең конструктив ысулларына һәм чараларына ия булу. Балаларда сөйләм теленең барлык компонентларын: сөйләмнең грамматик төзелешен, бәйләнешле сөйләмне – аның диалогик һәм монологик формаларын үстерү; сүзлек запасы формалаштыру, сөйләмнең аваз культурасын тәрбияләү. Тәрбияләнүчеләрнең гамәли рәвештә сөйләм нормаларына ия булуы.

Балада туган теленә карата кызыксыну уяту. Уен ситуацияләре, мәгълүмати-аралашу технологияләре куллану, балалар эшчәнлегенең төрле төрләрен (уен, аралашу, нәтиҗәле эшчәнлек төрләрен) оештыру аша сөйләмне аңлау һәм туган телдә сөйләшәсе килү теләге уяту.Туган телендә аралашуны үзләштерү өчен шартлар булдыру.

Авазларны дөрес әйтү, сәнгатьле сөйләм нигезләрен формалаштыру.

***Комплекслы – тематик план***

| Ай | Атна | Эшчәнлек темасы | Бурычлар |
|---|---|---|---|
| сентябрь | I | "Безнең төркемдәге уенчыклар" | Төркемдәге уенчыкларны карау, уен вакытында бер-беренэ карата дуслык мөнәсәбәтләре, уенчыкларга карата сакчыл караш тәрбияләү, сөйләм телен үстерү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | II | «Песи һәм песи балалары» | Рәсем буенча кечкенә хикәя төзергә өйрәтүне дәвам итү, песине тасвирлау, хайваннарга карата сакчыл караш тәрбияләү. |
| | III | “Уенчыкны тасвирла” | Уенчыкларны тасвирларга өйрәтү, сөйләм телен үстерү, уенчыкларга карата сакчыл караш тәрбияләүне дәвам итү. |
| | IV | “Безнең төркемдәге уенчыклар” | Уенчыкларны карауны бүлешеп, дус – тату уйнарга өйрәтүне дәвам итү, уенчыкларны ватмаска өндәү, сөйләм телен үстерү. |
| октябрь | I | “Сузык авазлар” | Сузык авазлар белән таныштыру, сузык авазларга башланган сүзләрнеэзләп табу. |
| | II | “Тел көрмәкләндерү” | Тел көрмәкләндерүче җөмләләр өстендә эш, сөйләм телен үстерү. |
| | III | “Сюҗетлы-ролле уен “Ярмарка” | Җиләк – җимеш һәм яшелчәләр турында белемнәрен камилләштерү, диалог корып сөйләшергә өйрәтү. |
| | IV | “Хайваннар кышка ничек әзерләнә?” | “Хайваннар кышка ничек әзерләнә?” рәсеме буенча хикәя төзү.<br>Кечкенә генә хикәя төзергә өйрәтү. |
| ноябрь | I | “Шәхси тәҗрибәдән чыгып сөйләү. Дидактик уен«Курчакка бүлмә әзерлик» | Өй џиһазлары турында белемнәрен үстерү,аларның атамаларын дөрес әйтү, әһәмиятләрен билгеләү, үз фикереңне әйтә белү күнекмәләре формалаштыру, сөйләм телен үстерү. |
| | II | “Рәсем буенча сөйләү «Эт һәм эт балалары» | Рәсем буенча бәйләнешле хикәя төзергә өйрәтүне дәвам итү, шәхси тәҗрибәдән чыгып кечкенә хикәя төзү күнекмәләрен камилләштерү. |
| | III | “Уенчыкка тасвирлама” | Уенчык буенча кечкенә тасвирлама төзү, сүзләрдә [ш], [ч],[л] авазларын дөрес әйтү, тавыш тембрын көйли белергә өйрәтү. |
| | IV | “Курчакларга тасвирлама һәм чагыштыру” | Курчакларга тасвирлама бирә һәм чагыштыра алу күнекмәләрен камилләштерү, җөмләне азакка кадәр төзеп бетерегә өйрәтүне дәвам итү. |
| декабрь | I | ”Кыш җитте” | Тирә-юнь белән таныштыруны дәвам итү. Кыш турында зур рәсем карау, эчтәлеге буенча сорауларга җавап алу. Ике-өч җөмләдән торган хикәя төзергә өйрәтү, кышкы киемнәрне тасвирлау, кием төшенчәсен ныгыту. |
| | II | “Уенчыклар турында сөйләшү” | Кыска хикәяләр төзергә өйрәтүне дәвам итү, авазларны дөрес әйтү өстендә эшләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | III | “Картина буенча сөйләү” “Таня суыктан курыкмый” | Картина буенча кечкенә хикәя төзергә өйрәнү, бирелгән аваз белән сүзләр табу, сүзләрдәге авазларны билгеләү. |
| | IV | “Кыш. Калын һәм нечкә К авазы” | Яңа сүзләр белән таныштыру. Рәсемнәр күрсәтеп аңлату: кар бабай, Кыш бабай, чыршы бәйрәме, Яңа ел, бүләк, өләшә, тарата. Кыш турында табышмаклар өйрәнү. калын һәм нечкә К авазының әйтелеше өстендә эшләү. |
| гыйнвар | I | “Ап- ак тунлы кыш” | Балаларның кыш турындагы белемнәрен киңәйтү, сөйләм телен үстерү, балаларда кызыксыну, бердәм хезмәт хисләре тәрбияләү. |
| | II | “Кышкы уеннар” | Кыш турындагы белемнәрен киңәйтү, бәйләнешле сөйләм телен үстерү, кышкы уеннар белән таныштыруны дәвам итү. |
| | III | “Кыргый хайваннар” | Кыргый җәнлекләртурындагы белемнәрен формалаштыруны дәвам итү, сөйләмнең грамматик төзелешен камилләштерү, сак караш тәрбияләү. |
| | IV | Ә. Кари “Кыш” | Шигырьнең өзеген ятлау, сөйләм телен үстерү, кыш ел фасылына хас билгеләрдән алгоритм төзү. |
| февраль | I | “Җир өсте, һава,су транспорты” | Балаларда урамда игътибарлылык һәм  транспорт хезмәткәрләренә ихтирам тәбияләү; транспорт турында күзаллауларын киңәйтү, фикерләү сәләтен үстерү.Балаларны транспорт төрләре белән таныштыруны дәвам итү, исемнәрен истә калдыру, кулланылышын белү. Сөйләм телен үстерү. |
| | II | М.Җәлил “Карак песи” | Балаларда патриотик хисләр тәрбияләү. Шигырне сәхнәләштерү аша балаларда артистлык күнекмәләрен үстерү. М.Җәлил турында балаларның белемнәрен баету, аның әсәрләре белән танышуны дәвам итү. Әйтелешләре авыр сүзләр өстендә эшләү. |
| | III | “Очучылар” | Балаларны очкычның олешләрен, зурлыгын, формасын аерырга һәм атарга өйрәтүне, исемнәрне сыйфатлар белән яраклаштыру күнекмәләре формалаштыруны, (У) сузык авазан әйтүдә күнектерүне дәвам итү, төрле гаскәр төрләренә, очучы һөнәренә хөрмәт, патриотлык хисләр тәрбияләү. |
| | IV | “Хәрби һөнәрләр” | Хәрби һөнәрләр, аларның төрләре, хәрби техника турында белемнәрен формалаштыру, хәрби һөнәрләргә карата хөрмәт тәрбияләү. Кайбер авазлар өстендә эшләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| март | I | “Әниләр бәйрәме” | Әниләр бәйрәме турында белемнәрен киңәйтү, әниләр турында тасвирлау хикәясе төзергә өйрәтү; әниләргә мәхәббәт һәм ярдәм итү теләге тәрбияләү. |
| | II | “Эт көчекләре белән” | Сюжетлы картинаның персонажларын игътибар белән карау, эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирү, сөйләмне сыйфатлар куллану хисабына баету. |
| | III | “Бияләй һәм перчатка” | Татар халкының кул эшләре белән таныштыру, тәрбиячөнең сөйләмен аңларга, сорауларга җавап бирергә өйрәтүне дәвам итү. |
| | IV | “Халкыбыз мирасы белән кызыксыну” | Әби-бабаларыбыз иҗат иткән әйберләргә хөрмәт тәрбияләү. Татар халкының декоратив- кулланма сәнгать үрнәкләре белән таныштыру. Бәйләнешле сөйләм телен үстерү. |
| апрель | I | “Аюның язгы маҗаралары” | Балаларны исем, сыйфат кулланып гади җөмләләр төзергә өйрәтү, язның төп билгеләрен ныгыту, бирелгән сүзләргә антонимнар сайлауны формалаштыру. |
| | II | “ Күчмә кошлар” | Кошларга сакчыл караш тәрбияләү. Балаларның кошлар турындагы белемнәрен ныгыту. Күчмә кошларның исемнәрен дөрес итеп әйтергә өйрәтү. |
| | III | “Урман күлендә” | Балаларның “с”, “з”, “у”, “ш” авазларын дөрес әйтүләрен ныгыту, язның төп билгеләре, айлары, табигать күренешләре турындагы белемнәрен ныгыту. |
| | IV | “Габдулла Тукай шигырьләре” | Шагыйрьнең иҗатына ихтирам хисләре тәрбияләү. Балаларны Тукайның тормыш  һәм иҗат юлы белән таныштыру. Әдәби әсәрләрне тыңлый һәм сөйли белүләренә ирешү. |
| май | I | “Җиңү бәйрәме” | Транспорт төрләре белән таныштыруны дәвам итү, Җиңү көне уңаеннан транспорт турындагы күзаллауларын формалаштыруны дәвам итү, ветераннарга карата хөрмәт, горурлану хисләре һәм коллективта эшләүтеләге уяту. |
| | II | “Бөҗәкләр” | Балаларны бөҗәкләр турындагы күзаллауларын формалаштыруны дәвам итү, сөйләмнең грамматик төзелешен камилләштерү. |
| | III | “Йорт хайваннары турында сөйләшү” | Хайваннарны тасвирлый белү, бирелгән сорауларга тулы җавап табу күнекмәләрен үстерүне дәвам итү. |
| | IV | “Чәчәкле җәй” | Җәй ел фасылына хас билгеләр белән таныштыруны дәвам итү, предметлы картиналар буенча “Җәй” темасына хикәя төзү осталыгын үстерү. |

***“Сәнгәти – эстетик үсеш” белем бирү өлкәсе.***

Сәнгати – эстетик үсеш сәнгать әсәрләрен, табигать дөньясын кыйммәт – мәгънә ягыннан кабул итү һәм аңлау алшартлары үсешен; әйләнә – тирә дөньяга карата эстетик мөнәсәбәт барлыкка килүне; сәнгать төрләре турында элементар күзаллаулар формалашуны; музыканы, матур әдәбиятны, фольклорны аңга кабул итүне; әдәби әсәрләр персонажларның кичерешләрнен уртаклашуны стимуллаштыруны; балаларның мөстәкыйль иҗади эшчәнлеген гамәлгә ашыруны күздә тота.

***Музыкаль эшчәнлек.***

Музыкаль сәнгатькә тарту; музыка сәнгатен кыйммәт – мәгънә ягыннан кабул итү һәм аңлау алшартларын үстерү; музыкаль культура нигезләрен формалаштыру, элементармузыкаль төшенчәләр, ңанрлар белән таныштыру.

| январь | «Пескәй »<br>1. “Пескәй уяна”. Ятып, бергә уң аякны һәм сул кулны күтәрәләр, төшерәләр. Аннан сул аякны һәм уң кулны күтәрәләр, төшерәләр. Аннан 2 кулны һәм 2 аякны бергә күтәрәләр, төшерәләр. 4-5 тапкыр кабатларга.<br>2. «Пескәй сөенә». Үрмәләү позасына керергә. Башны күтәрергә, умыртка сөяген бөгәргә. Тирән сулыш алырга. 4-5 тапкыр кабатларга.<br>3.«Пескәй ачулана ». Үрмәләү позасына керергә. Иякне күкрәккә тидерергә, арканы бөгәргә. Тирән сулыш алырга. 4-5 тапкыр кабатларга.<br>4. “Пескәй сузыла” Сузылу күнегүе.<br>5. “Пескәй сикерә” Сикерү. |
| февраль | “Чәчәк”<br>Чәчәк йоклый,<br>Чәчәк уяна. (киерелү күнегүләре)<br>Иртәнге кояшка<br>Ул бик куана. (урында сикерү)<br>Кояшка сузыла (аяк очларына басып, сузылалар)<br>Кояшка үреләә (аяк очларына басып, сузылалар)<br>Күбәләк дустына (кулларны канатлар каккан кебек җилпиләр) |

| | |
|---|---|
| | Сәлам өләшә (сәлам бирәләр) |
| март | Без уяндык, (киерелү күнегүләре)<br>Күзләрне ачтык, (күзләрен ачалар)<br>Аякларны суздык (аякларын сузып, селкетәләр)<br>Аларны да уяттык!<br>Ян –якка борылып (басып, ян –якка борылалар)<br>Кояшка без карадык. (аяк очларына басып, сузылалар)<br>Якты көнгә сокланып,<br>Матур итеп елмайдык. (ян – якка борылып, елмаялар)<br>Сикереп тә алдык (сикерү күнегүләре)<br>Йөгердек тә (урында йөгерү)<br>Хәзер инде без<br>Уйнарга бергә әзер! (үз-үзеңне кочу) |
| апрель | Аякларың тыпырдат (аякларны тыпырдаталар)<br>Кулларыңны чәбәклә.(кулларны чәбәклиләр)<br>Бер монда, бер монда,<br>Кыен эш түгел бер дә. (ян-якка борылып кулларны чәбәклиләр)<br>Башың аска иеп ал, (башларын бер иеп, бер күтәрәләр)<br>Кулларыңны болгап ал. (йөзү күнегүләре)<br>Бер монда, бер монда,<br>Кулларыңны болгап ал.(ян- якка борылып, йөзү күнегүләре эшлиләр)<br>Бу дустың белән күреш, (уңга борылып, сәләм юллыйлар, елмаялар)<br>Бу дустың белән күреш.(сулга борылып, сәләм юллыйлар, елмаялар)<br>Йә иптәш, йә, әйлән, (урында сикереп, әйләнәләр)<br>Бик кыен түгел бу эш. |
| май | Нәниләр бара тигез юл буйлап. (урында атлыйлар)<br>Тигез юл буйлап, ашыкмый атлап. (урында атлыйлар)<br>Зур-зур ташларны<br>Сикереп үтәләр. (урында сикерәләр) |

| | |
|---|---|
| | Уңга да баралар, сулга да баралар, (уңга – сулга борылу күнегүләре)<br>Су аша йөзеп, (йөзү күнегүләре)<br>ярга чыгалар. (сулыш алу күнегәләре) |

***Саф һавада хәрәкәтле уеннар***

Хәрәкәтле уеннар балаларның физик үсешенә булыша, сәламәтлекләрен ныгыта, хәрәкәт координациясен яхшырта. Әлеге уеннар ярдәмендә бала тырыш, көчле, сәләтле, нык ихтыярлы булып үсә. Бу уеннарны уйнаганда билгеле бер кагыйдәләрнең үтәлү мәҗбүрилеге балаларны тәртипкә, үз эш гамәлләр, хәрәкәтләрен барларга өйрәтә. Уенның шартларын истә калдыру аша балаларда күзәтүчәнлек тәрбияләнә, истә калдыру сәләте, хәтер эшчәнлеге яхшыра. Уен бапрышанда балалар бергәләп уйнау, хәрәкәт итү, ситуацияне хәл итү кебек күнекмәләргә өйрәнәләр, башка балалар арасында үзеңне тоту, гомуми кагыйдәләргә буйсыну кебек тәртип кагыйдәләрен үзләштерәләр.

***Комплекслы-тематик план***

| Ай | Атна | Тема | Бурычлар |
|---|---|---|---|
| сентябрь | I | «Аю өне янында»<br>”Куяннар һәм бүре” | Сикерү күнекмәләрен үстерү, сыгынучанлыкны, җитезлекне булдыру, сиганал буенча хәрәкәтләрне төгәл башкарырга өйрәтү. |
| | II | «Светофор һәм автомобиль» | Бирелгән темп белән хәрәкәтләнергә өйрәтүне дәвам итү. Юлдагы куркынычсызлык кагыйдәләрен ныгыту. |
| | | «Трамвай” | Игътибарлыкларын тупларга күнектерү, түземлек тәрбияләү, уен кагыйдәсен үтәргә өйрәтү. |
| | III | «Огуречик»<br>“Көтүче һәм көтү” | Йөгерү тизлеген үстерү,сигнал буенча хәрәкәт итү,шигырь сүзләренә туры китереп уйнау, күзәтүчәнлекне үстерү. |
| | IV | «Песи һәм тычкан» | Пространствода ориентлашу, бәрелми – төртелми уйнауны булдыру. |
| | | “Очкычлар” | Төрле юнәлештә йөгерү күнекмәләрен системалаштыру, дус –тату уйнауны булдыру. |
| Ок тяб | I | “Ябалак” | Игътибарлылык, кыюлык, җитезлек кебек матур сыйфатлар тәрбияләү, шигырь сүзләренә туры китереп уйнау. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | “Төсле автомобильләр” | Юл йөрү кагыйдәләрен ныгыту, төсләр турында белемнәрен камилләштерү, сиганал буенча хәрәкәтләнүне булдыру |
| | II | “Кыңгырау” | Дус – тату уйнауны булдыру, түгәрәк тирәли сиганал буенча йөгерү күнекмәләрен, тизлекне  үстерү, |
| | | “Инеш аша сикереп чык” | Урыннан 2 аякта ераклыкка сикерү күнекмәләрен камилләштерү, кыюлык тәрбияләү |
| | III | “Куяннар” | Сикерү күнекмәләрен камилләштерү, уен барышында иптәше белән хәрәкәтләрне яраклаштырып башкару күнекмәсен үстерү. |
| | | “Машиналар һәм җәяүлеләр” | Юл йөрү кагыйдәләре турында белемнәрен ныгыту, тирә-якта ориентлашу күнекмәсен үстерү,игъбарлылык тәрбияләү |
| | IV | “Беренче булып бас” | Игъбарлылык тәрбияләү, тырышлык, максатчанлык кебек яхшы сыйфатларны үстерү, физик активлыгын камилләштерү. |
| | | “Аю-бүре” | Йөгереклек һәм җитезлек сәләтен үстерү,сүзләргә туры китереп хәрәкәтләр ясау. |
| ноябрь | I | “Казлар - аккошлар” | Игътибарлыкларын, хәтерен, кузаллауларын үстерү, рольләрне бүлешкәннән соң дөрес башкаруны булдыру, пространствода бәрелешмичә төрле юнәлештә йөгерү күнекмәләрен камилләштерү. |
| | | “Сиздермичә йөгереп үт” | Сизгерлек булдыру, дус –тату унарга өйрәтүне дәвам итү. |
| | II | “Тавык кетәклегендә төлке” | Җитезлек, өлгерлек тәрбияләү, тиз йөгерү, сикереп менү күнекмәләрен бирү. |
| | | “Үз төсеңне тап” | Хәтерне, җитезлекне үстерү,балаларны иптәшләренә карата кайгыртучан, игътибарлы, ярдәмчел булырга өйрәтүне дәвам итү, кешелеклелек хисләре тәрбияләү. |
| | III | “Көн-төн” | Коллективта бергә уйнау теләге уяту, пространствода ориентлашу булдыру, сигналларга игътибар итү, ишетү сәләтен үстерү. |
| | | «Светофор һәм автомобиль» | Бирелгән темп белән хәрәкәтләнергә өйрәтүне дәвам итү. Юлдагы куркынычсызлык кагыйдәләрен ныгыту. |
| | IV | “Бүләкләр” | Балаларны бер-берсе белән аңлашып кирәк чакта ярдәм итеп уйнарга өйрәтүне дәвам итү, хәрәкәт активлыгын үстерү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | “Әбәк” | Игътибарлыкларын, хәтерен, кузаллауларын үстерү, рольләрне бүлешкәннән соң дөрес башкаруны булдыру, пространствода бәрелешмичә төрле юнәлештә йөгерү күнекмәләрен камилләштерү. |
| декабрь | I | “Песи һәм кошчыклар” | Хәрәкәт координациясен, җитезлекнее үстерү, уен белән кызыксындыру булдыру. |
| | | “Кайда шалтыраттылар” | Ишетү сәләтен үстерү,реакцияләренең тизлеген көчәйтү. |
| | II | “Кем беренче?” | Йөгерү тизлеген үстерү, максатка ирешүчәнлек кебек яхшы сыйфатлар тәрбияләү. |
| | | “Машиналар һәм җәяүлеләр” | Юл йөрү кагыйдәләре турында белемнәрен ныгыту, тирә-якта ориентлашу күнекмәсен үстерү,игъбарлылык тәрбияләү |
| | III | “Аучы һәм куяннар” | Сабырлык, җитезлек, хәрәкәт активлыгы тәрбияләү, пространствода оринтлашу булдыру, рольләрне бүлешеп уйнау күнекмәләрен үстерү. |
| | | “Кегляны аудар” | Төзлекне, тырыш, көчле, сәләтле, нык ихтыярлы булып үсүләренә этәргеч бирү. |
| | IV | “Мине куып җит” | Җитезлекләрен үстерү, бер –бер артлы йөгерү күнекмәләрен булдыру. |
| | | “Тавык кетәклегендә төлке” | Җитезлек, өлгерлек тәрбияләү, тиз йөгерү, сикереп менү күнекмәләрен бирү. |
| январь | I | “Миңлебай” | Яшьтәшләре белән зур булмаган төркемнәрдә, үзләре белеп, татар халык уеннарын оештыруда мөстәкыйльлекләрен үстерү, уен кагыйдәсен үтәүне булдыру. |
| | | “Аксак төлке” | Бер аякта сикерү кәнекмәләрен үстерү, җитезлек тәрбияләүне дәвам итү. |
| | II | “Энә һәм җеп” | Җитезлек, өлгерлек тәрбияләү, бер-бер артлы йөгерү күнекмәләрен үстерү. |
| | | “Бүре һәм сакрыклар” | Түгәрәккә басарга, күмәк уйнарга, хәрәкәтләрне дөрес итеп башкарырга күнектерүне дәвам итү. |
| | III | “Оядагы кошлар” | Сизгерлек, сигнал буенча хәрәкәт итү күнекмәләрен тәрбияләү. |
| | | “Үз парыңны тап” | Төрле юнәлештә йөгереп, сигнал булгач, үз парыңны табу күнекмәләрен үстерү, дус – тату уйнауны булдыруны дәвам итү. |
| | IV | “Чүлмәк сатам” | Яшьтәшләре белән зур булмаган төркемнәрдә, үзләре белеп, татар халык уеннарын оештыруда мөстәкыйльлекләрен үстерү, уен кагыйдәсен үтәүне булдыру. |
| | | “Тизрәк түгәрәккә | Музыканы игътибар белән тыңлау күнекмәләре булдыру, музыкка туктагач тәгәрәк |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | кер” | эченә кереп басарга өйрәтү, җитезлек, хәрәкәт активлыгын формалаштыру. |
| февраль | I | “Машиналар һәм җәяүлеләр” | Юл йөрү кагыйдәләре турында белемнәрен ныгыту, тирә-якта ориентлашу күнекмәсен үстерү,игъбарлылык тәрбияләү. |
| | | “Кегляны аудар” | Төзлекне, тырыш, көчле, сәләтле, нык ихтыярлы булып үсүләренә этәргеч бирү. |
| | II | “Төлке килә” | Сигнал буенча хәрәкәтләнү күнекмәләрен камилләштерү, сизгерлекләрен үстерү. |
| | | “Кыш бабай” | Сизгерлек, сигнал буенча хәрәкәт итү күнекмәләрен тәрбияләү. |
| | III | “Чаналар белән ярыш” | Җитезлекне, тизлекне булдыруны дәвам итү, дус –тату уйнау теләкләре тудыру. |
| | | “Соры бүре” | Күмәк уенда катнашасы килү теләге уяту, сак атлап йөрүче бүре образын хәрәкәтләр аша чагылдырырга омтылыш тудыру. |
| | IV | “Кошлар очалар” | Хәрәкәт тизлеген үстерүне дәвам итү, төрле юнәлештә очу күнегүләрен башкарып йөгерү, сигналларга игътибар итүне булдыру. |
| | | “Светофор” | Светофорның төсләре турындагы белемнәрен ныгыту, игътибарларын үстерү, уйлап эш итәргә өйрәтү. |
| март | I | “Кем әйберне тизрәк күчерә?” | Тизлек, сизгерлек үстерү, дус –тату уйнауны булдыруны дәвам итү,күрсәтелгән хәрәкәтләрне төгәл итеп башкарырга өйрәтүне дәвам итү. |
| | | “Тизрәк түгәрәккә кер” | Музыканы игътибар белән тыңлау күнекмәләре булдыру, музыкка туктагач тәгәрәк эченә кереп басарга өйрәтү, җитезлек, хәрәкәт активлыгын формалаштыру. |
| | II | “Инеш аша сикереп чык” | Урыннан 2 аякта ераклыкка сикерү күнекмәләрен камилләштерү, кыюлык тәрбияләү. |
| | | “Үрдәк атыш” | Тупны тотарга, туптан качарга өйрәтүне дәвам итү, төз атуны булдыру, балаларның хәрәкәтчәнлекләрен, җитезлекләрен үстерү. |
| | III | “Флагка кадәр сикер” | Сикерү күнекмәләрен үстерү, сыгынучанлык, чыдамлылык булдыру, бирелгән темп белән хәрәкәтләнергә өйрәтүне дәвам итү. |
| | | «Төсләр сату » | Йөгерү тизлеген үстерү, пространствода ориентлашу күнекмәләрен, төсләр турында белемнәрен камилләштерүне дәвам итү. |
| | IV | “Үз парыңны тап” | Төрле юнәлештә йөгереп, сигнал булгач, үз парыңны табу күнекмәләрен үстерү, дус – тату уйнауны булдыруны дәвам итү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | “Миңлебай” | Яшьтәшләре белән зур булмаган төркемнәрдә, үзләре белеп, татар халык уеннарын оештыруда мөстәкыйльлекләрен үстерү, уен кагыйдәсен үтәүне булдыру. |
| апрель | I | “Бүре һәм сакрыклар” | Түгәрәккә басарга, күмәк уйнарга, хәрәкәтләрне дөрес итеп башкарырга күнектерүне дәвам итү. |
| | | “Тупны тәгәрәт” | Тупны предметлар аша тәгәрәтү, максатка ирешүчәнлек, башлаган эшне азагына кадәр эшләп чыгу күнекмәләрен үстерү. |
| | II | “Чиләк белән бакалар” | Сикерү тизлеген үстерү, сигнал буенча хәрәкәт итү, пространствода ориентлашу, тизлек булдыруны дәвам итү. |
| | | “Флагка кадәр йөгер” | Йөгерү тизлеген үстерүне дәвам итү, бер – бер артлы сигнал буенча йөгерү күнекмәләрен камилләштерү. |
| | III | “Тавык кетәклегендә төлке” | Җитезлек, өлгерлек тәрбияләү, тиз йөгерү, сикереп менү күнекмәләрен бирү өстендә эшне дәвам итү. |
| | | “Әбәк” | Игътибарлыкларын, хәтерен, кузаллауларын үстерү, рольләрне бүлешкәннән соң дөрес башкаруны булдыру, пространствода бәрелешмичә төрле юнәлештә йөгерү күнекмәләрен камилләштерү. |
| | IV | “Бал кортлары” | Йөгерү күнекмәләрен үстерүне дәвам итү, пространствода ориентлашуны камилләштерү. |
| | | “Куяннар” | Сикерү күнекмәләрен камилләштерү, уен барышында иптәше белән хәрәкәтләрне яраклаштырып башкару күнекмәсен үстерү. |
| май | I | “Беренче булып бас” | Игъбарлылык тәрбияләү, тырышлык, максатчанлык кебек яхшы сыйфатларны үстерү, физик активлыгын камилләштерү. |
| | | “Тупны, сикертеп, алып бар” | Тупны сикертеп алып барырга өйрәтә башлау, максатчанлык, батырлык сыйфатлары тәрбияләү. |
| | II | «Трамвай” | Игътибарлыкларын тупларга күнектерү, түземлек тәрбияләү, уен кагыйдәсен үтәргә өйрәтү. |
| | | “Буш урын” | Күзәтүчәнлекләрен, игътибарлыкларын үстерү, этешми-төртешми уйнау күнекмәләрен камилләштерү. |
| | III | “Чүлмәк сатам” | Яшьтәшләре белән зур булмаган төркемнәрдә, үзләре белеп, татар халык уеннарын оештыруда мөстәкыйльлекләрен үстерү, уен кагыйдәсен үтәүне булдыру. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | “Очкычлар” | Төрле юнәлештә йөгерү күнекмәләрен системалаштыру, дус –тату уйнауны булдыру. |
| | IV | “Тизрәк түгәрәккә кер” | Музыканы игътибар белән тыңлау күнекмәләре булдыру, музыкка туктагач тәгәрәк эченә кереп басарга өйрәтү, җитезлек, хәрәкәт активлыгын формалаштыру. |
| | | “Соры бүре” | Күмәк уенда катнашасы килү теләге уяту, сак атлап йөрүче бүре образын хәрәкәтләр аша чагылдырырга омтылыш тудыру. |

**“СОЦИАЛЬ-ШӘХСИ ҮСЕШ”** ***БЕЛЕМ БИРҮ ӨЛКӘСЕ.***

***Хезмәт.***

«Хезмәт» белем бирү эшчәнлеге эчтәлеге балаларда хезмәткә уңай мөнәсәбәт формалаштыру максатын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.

Татар халык әкиятләре ярдәмендә хезмәт эшчәнлеге турында күзаллаулар формалаштыру. Баланың эш барышын татар шагыйрьләренең хезмәт турындагы шигырьләре белән бәйләү.

Балаларга аңлаешлы һөнәрләр (төзүче, электрик, сантехник һ. б.) белән таныштыруны дәвам итү. Өлкәннәрнең хезмәт чичәнлегенең мәгънәсе турында күзаллаулар формалаштыру. Хезмәт эшчәнлегенең төп бурычы булып тора. Бу бурычны тормышка ашыру түбәндәге мәсьәләләрне чишү аша башкарыла:

- зурлар хезмәте белән танышу, хезмәтнең җәмкыятькә кирәклеге һәм файдасы турында күзаллауларын формалаштыруҺәм кеше хезмәтенә хөрмәт, хезмәтнең нәтиҗәсенә сак караш тәрбияләү;
- балаларның хезмәт эшчәнлеген оештыру, эш тәҗрибәсе , эшне оештыру, зурлар һәм яшьтәшләре белән үзара уңай мөнәсәбәтләр урнаштыру күнекмәләрен камилләштерү.

***Комплексы-тематик план***

| Тема | Интеграция |
|---|---|
| ***Сентябрь*** | |
| 1. Үзлегенннән киенү – чишенү, киемнәрне шкафка тәртип белән җыеп кую күнекмәләрен формалаштыру.<br>2. Балаларны төркемдә һәм балалар бакчасы уен җирлегендә тәртип урнаштыру буенча кызыксындыру.<br>3. Үзлегеннән бүлмә һәм җирлек гөлләренә су сибү теләкләрен уяту.<br>4. Балаларның кул эшләренә теләкләрен уяту: тәрбиячегә китапларны һәм дидактик материалларны ремонтларга булышу. | *Уку:* профессияләр турында хикәяләр уку, шофёр профессиясе буенча рәсемнәр карау<br>*Аралашу:* балалар бакчасынбa азык – төлек алып килүче машиналарны күзәтү, күргәннәр буенча әңгәмә оештыру. |
| ***Октябрь*** | |
| 1. Үзлегенннән киенү – чишенү, киемнәрне шкафка тәртип белән җыеп кую күнекмәләрен камилләштерү.<br>2. Үзлегеннән төркемдә һәм балалар бакчасы уен җирлегендә тәртип урнаштыру күнекмәләрен өйрәнүне дәртләндерү.<br>3. Балаларда балалар бакчасы хезмәткәрләренә ярдәм итү теләкләрен уяту (урындыклар һәм өстәлләр өстеннән тузан сөртү, сөлгеләрне һәм урын – җир өстен алмаштырырга ярдәм итү).<br>4. Өстәлне иртәнге һәм көндезге ашка әзерләргә ярдәм итү теләкләрен формалаштыру (клакларны, чәнечкеләрне, стаканнарны кую).<br>5. Сюжетлы-рольле уен «Шофёр» | *Сәламәтлек:* үз – үзеңне тәртиптә тотарга кызыксындыру, шәхси гигиена таләпләрен үтәргә өйрәтү.<br>*Куркынычсызлык:* хезмәт кирәк – ярақларыннан дөрес куллану һәм аларны дөрес урнаштыру күнекмәләрен фолмалаштиыру. |
| ***Ноябрь*** | |
| 1. Үзлегенннән киенү – чишенү, киемнәрне шкафка тәртип белән җыеп кую күнекмәләрен камилләштерү не дәвам итү, курчак киемнәрен юу һәм киптерергә өйрәтү.<br>2. Үзлегеннән төркемдә һәм балалар бакчасы уен җирлегендә тәртип урнаштыру күнекмәләрен өйрәнүне системалаштыру.<br>3. Балаларны бүлмә гөлләрен утырту һәм аларны тәрбияләү өстендә эшләүне тарту. | *Уку:* повар профессииясе турында хикәяләр уку, рәсемнәр карау.<br>*Аралашу:* балалар бакчасы кухнясына экскурсия, повар эшен күзәткәннән соң, хикәя төзергә өйрәтү.<br>*Социальләштерү:* кушылган эшкә карата җаваплылык формалаштыру . |

| | |
|---|---|
| ***Декабрь*** | |
| 1. Үзлегенннән киенү – чишенү, киемнәрне шкафка тәртип белән җыеп кую күнекмәләрен системалаштыру.<br>2.Үзлегеннән төркемдә һәм балалар бакчасы уен җирлегендә тәртип урнаштыру күнекмәләрен камилләштерү (сезонлы эш–җирлекне кардан арындыру) .<br>3. «Кухняда поварлар эше» дигән экскурсияне дәвам итү. | *Социальләштерү:* балаларны шәхси һәм тәркемләп кушылган эшләрне үтәргә тарту, бер – берсе арасында тәрбияче ярдәме белән эшне бүлергә өйрәтү.<br>*Уку:* зурлар хезмәтенең киршклеге турында хикәяләр уку, зурлар хезмәтен хөрмәт итү турында үрнәк китерү.<br>*Аралашу:* хезмәтнең җәмгыять, гаилә һәм балалар бакчасы өчен кирәклеге турында сөйләшү. |
| ***Январь*** | |
| 1. Балаларны һәр эштә, кыяфәттә җыйнак булырга теләк уяту, шәхси билгедә тәрбияләү.<br>2. Зурлар ярдәме белән киемнәрне тәртиптә тоту күнекмәләрен формалаштыру (чистарту, киптерү).<br>3. Үзлегеннән зурларга ярдәм итү теләге уяту. | *Социальләштерү:* башланган эшне азагына кадәр эшләүне тәрбияләү, аны яхшы эшләүне булдыру.<br>*Аралашу:* врач хезмәте буенча сөйләшү, рәсемнәр карау, теманы тикшерү теләге уяту. |
| ***Февраль*** | |
| 1. Үзлегеннән төркемдә һәм балалар бакчасы уен җирлегендә тәртип урнаштыру күнекмәләрен камилләштерүне дәвам итү (сезонлы эш – җирлекне кардан арындыру, сукмакларга песок чәчү) .<br>2. Оештырылган белем эшчәнлегенә кирәк яраклар әзерләү теләкләрен формалаштыру.<br>3. Балаларнытабигать почмагында орлыклар утыртырга, гулләрне күчерергә тарту.<br>4. Дидактик уен «Әгәр куян авырса?» | *Куркынычсызлык:* карны күрәгәндә куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәүне формалаштыру.<br>*Танып белү:* табигатьпочмагындагы гөлләрнең һәм усемлекләрнеңисемнәрен белү. |
| ***Март*** | |

| | |
|---|---|
| 1. Үзлегеннән төркемдә һәм балалар бакчасы уен җирлегендә тәртип урнаштыру күнекмәләрен ныгыту.<br>2. Үзлегенннән киенү – чишенү, киемнәрне шкафка тәртип белән җыеп кую күнекмәләрен системалаштыруны дәвам итү.<br>3. Оештырылган белем эшчәнлегенә кирәк яраклар әзерләргә омтылыш тәрбияләү, деңурлык вазыйфаларын үтәүне булдыруны дәвам итү. | *Аралашу:* йорт хайваннарын караучы хезмәте турында сөйләшү. |
| ***Апрель*** | |
| 1.Дежур тору күнекмәләрен ныгыту, башланган эшне азагына кадәр эшләүне тәрбияләү .<br>2. Балалар бакчасы уен җирлегендә тәртип урнаштыру күнекмәләрен ныгыту (веранданы себерү, коелган ботакларны җыю).<br>3. Бакчада эшләүне булдыру. | *Уку:* С. Михалков«Почта», 1 өзеген ятлау.<br>*Аралашу:* балаларга почтальон (хат ташучы) хезмәте турында сөйләү. |
| ***Май*** | |
| 1.Үзеңә үзең хезмәт күрсәтү күнекмәләрен ныгыту.<br>2. Утырткан үсемлекләрне тәрҗияләүне дәвам итү.<br>3. Зурлар хезмәте турында (почтальон, врач, повар, шофер) белемнәрен камилләштерү.<br>4. Сюжетлы-рольле уеннар «Шофер», «Шифаханә» | *Аралашу:* үсемлекләрнең үсешен күзәтү, күргәннәр буенча сөйләшү.<br>*Социальләштерү:* уеннарда рольләрне дөрес башкаруны ныгыту. |

Белем өлкәсе “Социаль - шәхси үсеш” җәмгыятьтәге әхлак һәм әдәп кануннарын үзләштерүгә юнәлгән.
Планлаштыруинтеграция принциплары һәм төрле хезмәт һәм иҗат эшчәнлеге, көнкүрештәге куркынычсызлык кагыйдәләре формалаштыру буенча төзелгән ( ФГОС ДО).

***Куркынычсызлык.***

«Куркынычсызлык» белем бирү эшчәнлеге эчтәлеге үз тормышыңның куркынычсызлыгы нигезләрен һәм экологик аң (әйләнә-тирә дөнья куркынычсызлыгы) алшартларын формалаштыру максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.

***Тормыш куркынычсызлыгы нигезләрен формалаштыру.***

Балаларны балалар бакчасында көндәлек режим һәм үз- үзләрен тотуның иң элементар кагыйдәләре белән, бүлмәдә хәвеф-хәтәрсез йөрү кагыйдәләре белән таныштыруны дәвам итү.

Үз тормышың куркынычсызлыгы нигезләре турында белемнәрне үзләштерү, саклык, сизгерлек хисе тәрбияләү. Кайчы, пычак, очлы предметлар белән эш итүдә, спорт инвентаре, пыяла предметлар кулланганда сак булырга күнектерү.

Балаларны тормышта яңа, алар өчен гадәти булмаган очракларда, таныш булмаган кешеләр белән очрашканда үз-үзләрен дөрес тотарга өйрәтү.

***Юлларда хәвеф-хәтәрсез йөрү тәртибе формалаштыру.***

Юл хәрәкәтендә светофорның кызыл, сары, яшел төсләренең урнашу тәртибе һәм мәгънәләре белән таныштыру. Светофор сигналы буенча хәрәкәт итәргә күнектерү.

Балаларны юнәлешләрне (алга - артка, өскә - аска, уңга - сулга) аерырга гына түгел, шулай ук күрсәтелгән юнәлештә йөрергә, үзеңә карата теге яки бу әйбернең торышын (миннән сул якта - өй, унда - машина, алда - җәяүлеләр, артта - велосипедчы) билгеләргә өйрәтү.

Чагыштырмача хәрәкәт итү тизлеген (тиз, акрын) билгеләргә, транспорт чараларының (трамвай, автобус, янгын сүндерү машинасы, ашыгыч ярдәм машинасы һ. б.ның) тавыш сигналларын аерырга, тавыш чыганагының кайда булуын сиземләргә, кирәк очракта туктарга өйрәтү. Ишетү-хәрәкәт координациясен үстерү.

Кайбер җәмәгать транспортлары (троллейбус, автобус, трамвай, поезд, самолёт, теплоход һ. б.) турында күзаллауларны баету; маршрут транспорты (автобус, троллейбус, трамвай) тукталышы урыннарын билгеләү; «Автобус яки троллейбус тукталышы»н аңлатучы билге белән таныштыру. Җәмәгать транспортына утыру һәм аннан чыгу кагыйдәләренә игътибар итү.

Балаларга метрополитен, тимер юл, поезд, машинист хезмәте, тимер юлда һәм тимер юл транспортында үз-үзеңне тоту кагыйдәләре турында сөйләү. Тимер юл макеты белән таныштыру.

Урамда үз-үзеңне тотуның иң элементар кагыйдәләрен (йөгермәү, кычкырмау, тротуар кырыеннан йөрмәү һ. б.) үтәүгә ирешү. Җәяүле юлы белән, «җәяүлеләр юлы» билгесе белән таныштыру; урамны кайда һәм ничек аркылы чыгу турында, велосипедта йөрү кагыйдәләре турында аңлату.

Уңга һәм сулга борылышлар ясап, түгәрәк буенча, предметларны әйләнеп үтеп, өч тәгәрмәчле велосипедта йөрергә ойрәтүне дәвам итү. Үз хәрәкәтләре белән идарә итә белү, тормозга басып туктата алу күнекмәләрен үстерү. Спорт мәйданчыгында иркен ориентлаша белүне камилләштерү.

Транспорт чараларының охшаш һәм аермалы якларын табарга, билгеләнгән үзлекләре һәм функциональ үзенчәлекләре буенча чагыштырырга һәм төркемнәргә берләштерергә өйрәтү, алынган мәгълүматны гомумиләштерергә тырышуларын («Охшашны җый», «Оча, йөзә, йөри» һ. б.) хуплау.

Өлкәннәр хезмәте турындагы белемнәрен киңәйтү: троллейбус (автобус) йөртүче троллейбус (автобус) йөртә; кар җый-

гыч машинаны йөртүче юлларны кардан чистарта; ЮХИДИ инспекторы юлларда автомобильләр хәрәкәтен җайга сала һ. б.; эш төрләре һәм эш максаты арасында бәйләнешне ачыкларга ярдәм итү.

Балаларның, сюжетлы-рольле уенда юлда имин йөрү кагыйдәләрен чагылдыру өчен, мөстәкыйль рәвештә пред- метлы-уенлы мохит тудыруларын, модульләргә уен мәгънәсе бирүләрен, образлы һәм техник уенчыкларны, аларны алыштыручы алмаш предметларны куллануларын хуплау.

Балаларны уен ситуацияләрендә шартлы уйдырманың максатын аңларга, коллективта уен кагыйдәләренә яраклашып эш итәргә, игътибарлы булырга, уен персонажларының (транспорт йөртүчеләр, җәяүлеләр, пассажирлар һ. б.) роль буенча хәрәкәтләрен төгәлрәк башкарырга, ишетү һәм күрү сигналларына, әйләнә-тирәдәге көтелмәгән үзгәрешләргә тиз җавап бирергә, мөстәкыйльлек күрсәтергә һәм мәйданда ориентлашырга өйрәтү.

Мөстәкыйль дидактик уеннарда балаларның алган тәҗрибәләрен файдалануга шартлар тудыру. Төрле характердагы ял итү уеннары оештыру; юл йөрү кагыйдәләрен өйрәнү өчен әһәмиятле ситуацияләрне эченә алган уен-мавыгулар, курчак театры, сәхнәләштерелгән гади әсәрләр, уеннар өйрәнү.

Балаларда, шартлар буенча һәм үзләре уйлап тапканча, шәһәр (авыл) урамнары макетын төзү теләкләрен үстерү. Балаларны объектларның пространстводагы сурәтләмәләрен - озынлыкларын (биеклекләр, киңлекләрен) аера белү; деталь һәм аның өлешләренең урынын (өстән, астан, өстенә, астына һ. б.) билгеләүгә; объектларны (деталь һәм аның өлешләрен һ. б.ны) анализларга өйрәтү; тимер юллар, ике яклы хәрәкәт итү юллары, күперләр, гаражлар һ. б.төзүгә омтылышларын үстерү.

Балаларны табигать күренешләренә, тәүлектәге үзгәрешләргә һәм аларның әйләнә-тирәдә чагылышына (кич - урамда караңгы төшә - багана башларында фонарьлар яна, машиналар фараларын кабыза) игътибар итәргә өйрәтү.

Юлларда куркынычсыз йөрү кагыйдәләрен өйрәнү процессына кызыксыну уяту.

***Экологик аң алшартларын формалаштыру.***

Балаларны хайваннар белән очрашканда сак булырга өйрәтү, агулы үсемлекләрнең үзлекләре турында кисәтү.

Кайбер куркыныч сыеклыклар, газсыман матдәләр, ут, зарарлы ашамлыклар турында, витаминнар, дару препаратларын күп күләмдә кабул итүнең куркынычлыгы турындагы күзаллауларын үстерү.

***Комплекслы - тематик план***

| Ай | Атна | Тема | Бурычлар | Интеграция |
|---|---|---|---|---|
| сентябрь | I | Тема: «Светофор-безнең дус». Уен «Светофор | Светофор , светофорның төсләре турында белемнәрен ныгыту. Машина юлындаһәм тротуарда үз-үзеңне тоту кагыйдәләре булән танышуны дәвам итү. Урам 2 өлешкә бүленгән икәнлеге турында белемнәрен | *Иҗади сәнгать*: рәсем якиябыштыру «Светофор». *Уку*: А. Усачев «Домик у перехода» (ятлау) |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | мажаралары» | үстерү. | *Социаль – коммуникатив үсеш*: фикер йөртү : «Берүзем өйдә», «Берүзем урамда», рәсемнәр буенча кечкенә хикәя төзү. *Физик культура*: хәрәкәтле уен «Төсле автомобильләр» |
| | II | Тема: «Өйдәге куркынычсызлык чыганаклары» | Балаларны көнкүреш предметлары белән таныштыру, аларның сәламәтлеккә зыян китерергә мөмкинлекләре турында аңлату. Көнкүрештәге куркынычсызлык кагыйдәләрен ныгыту. | |
| | III | Тема: «Ачык тәрәзәләр» | Балаларга ачык тәрәзәләрнең һәм балконнарның куркынычлык тудыру турында аңлату. Транспорт төрләре белән танышуны дәвам итү. | |
| | IV | Тема: «Алдакчы кыяфәт» | Балаларга таныш булмаган кешеләр куркыныч янавы турында аңлату. Таныш булмаган кешеләрнең җәберләүләре вакытында үз-үзеңне дөрес тоту турында өйрәтү. 01, 02,03 телефоннарыннан дөрес куллану турында сөйләшү. | |
| Октябрь | I | Тема: «Урам белән танышу» | Шәһәр урамнары турында күзаллауларын киңәйтү. | *Социаль – коммуникатив һәм танып белү үсеше:* урамга экскурсия. Уен “Дөрес – дөрес түгел». *Сөйләм үсеше:* имитацион уен «Юл аркылы ничек дөрес чыгарга». *Уку*: В. И. Мирясова шигырьләре *Иҗади сәнгать*: рәсем «Машиналар юлда». *Сәламәтлек*: иртәнге гимнастиканың, чыныктыруның, спорт белән |
| | II | Тема: «Көтелмәгән очрашу» | Таныш булмаган балалар һәм яшүсмерләр белән аралашу кагыйдәләрен аңлату, 01,02,03 телефоннарын куллану кагыйдәләрен ныгыту. | |
| | III | Тема: «Юл йөрү билгеләре». *Дидактик уен* «Төс буеча сайла». *Имитацион уен* «Мин -шофер», *«Мин* - машина» | Юл йөрү билгеләренең әһәмияте турында өйрәтү. Юлда машина йөреше 2яклы булуын аңлату. «Җир асты юлы» билгесе белән таншышу. | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | IV | Тема: «Сәламәт буласың килсә...» | «Сәламәтлек төшенчәсе белән танышу». | шөгыльләнүнең файдасы турында сөйләшү<br>«ЗОЖ» төшенчәсе кертү;<br>һәлактләр булганда зурларга эндәшүнең кирәклеген аңлату “Зурлар безгә ярдәм итә” |
| ноябрь | I | Тема: «Светофорның 3 төсе».<br>*Дидактик уен* «Җәяүлеләр һәм транспорт» | Светофорның төшенчәсетурында белемнәрен ныгытую. Җәяүлеләрнең юлда йөрү кагыйдәләре буенча белемнәрен формалаштыру. | *Танып белү һәм сөйләм үсеше*:<br>Хикәя төзү «Юлда үзеңне ничек тотарга?”<br>*Җыр*: музыкаль-дидактик уен «Урамны тыңлыйбыз».<br>*Социальләштерү*: имитацион уен «Без автобуста».<br>*Иҗади сәнгать*: ябыштыру «Минем машинага гараж».<br>*Уку*: С. Маршак «Светофор» (ятлау).<br>Танып белү: рәсем буенча кеше төзелешен карау |
| | II | Тема: «Шәһәр буенча сәяхәт».<br>*Дидактик уен* «Юл йөрү кагыйдәләрен бел һәм үтә” | Шәһәрдә транспортта йөрү үзенчәлекләре белән танышу. | |
| | III | Тема: «Транспортта үз-үзеңне дөрес тоту». Уен «Без барабыз, барабыз.....» | “Куркынычсызлык утравы” билгесе һәм әһәмияте белән таныштыру. Җәмгыять транспортыннда үз-үзеңне дөрес тоту күнекмәләрен формалаштыруны дәвам итү. | |
| | IV | Тема: «Кешенең тән төзелеше» | Кешенең тән төзелеше турында таныштыру ( сулыш органнары, умыртка сөяге, ашказаны, кан әйләнеше) | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| декабрь | I | Тема: «Айболит дәресләре» | «Вирус, микроб» төшенчәләре кертү. Чирләрдән котылу чаралары белән таныштыру, авырганда терелә чаралары турында сөйләшү. Чыныктыру һәм витаминнарның файдасын аңлату. | *Аралашу:*хикәя төзү«Безгә“Ашыгыч ярдәм" машинасы килә».<br>*Уку:*К. Чуковский «Айболит» (уку һәм өзеген ятлау)<br>*Иҗади сәнгать: ябыштыру* «Безнең урамдагы автобус».<br>*Җыр:* имитацион уен«Мин машина».<br>*Уку:* А. Усачев«Дорожная песня»(ятлау) |
| | II | Тема: «Юлдагы ярдәмчеләр» | «Пешеходный переход», «Балалар» билгеләре турында белемнәрен камилләштерү. | |
| | III | Тема: «Әдәп кагыйдәләре» | Балаларның транспортта йөрү кагыйдәләре турында белемнәрен ныгыту. | |
| | IV | Тема: «Җәяүлеләр һәм йөртүчеләр». *Сюжетлы – рольле уен*«Мин шофер» | Шофер хезмәтетранспорт төрләре, аларның йөреше белән таныштыруны дәвам итү. | |
| январь | I | Тема: “Юл билгеләре”. | Балаларны юл йөрү кагыйдәләре һәм билгеләре белән таныштыруны дәвам итү, куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәүне булдыру. | *Иҗади сәнгать:*рәсем «Юлда әни белән» һәм ябыштыру «Грузовик».<br>*Аралашу:* әңгәмә” Кышкы юлда һәм сулыкларда үзеңне тоту кагыйдәләре”, ПДД буенча табышмаклар үткәрү.<br>*Уку:* А. Дорохова «Зеленый, желтый, красный».<br>*Социальләштерү:* бармак театры«Светофор”, юлдагы машиналарны күзәтү<br>*Хезмәт:* сукмакларга бозлавык вакытында песок сибү |
| | II | Тема: «Светофор» | Кыш көне сулыкларның үзенчәлекләре белән таныштыру, куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәүне булдыру. Балаларны юл йөрү кагыйдәләре белән таныштыруны дәвам итү, карточкалар белән эшләү. | |
| | III | Тема: “Урам киселеше”. | «Пешеходный переход», «Җир асты юлы» и «Сак бул: балалар» билгеләре белән таныштыруны дәвам итү, алар нинди әһәмияткә ия булуларын аңлату, белемнәрен баету. | |
| | IV | Тема: «Сак бул, бозлавык!» | Бозлы юлда сак йөрүне кисәтү, егылган кешегә беренче ярдәм күрсәтергә тәкъдим итү. | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| февраль | I | Тема: “Зеленый, желтый, красный” әсәрен уку. | Эчтәлеге буенча әңгәмә үткәрү, балалар белән юл кагыйдәләрен кабатлау.<br>Х/уен “Шоферлар”. | *Иҗади сәнгать*: ябыштыру «Машинага тәгәрмәчләр».<br>Уку: Т.Александрова «Светофорчик».<br>Аралашу: «Мин югалсам...» дигән темага әңгәмә оештыру.<br>*Физик культура*: «Нәрсә ул юл чаты?” дигән темага уеннар оештыру |
| | II | Тема: “Шәһәр транспорт төрләре”. | Балаларны 1 һәм 2 яклы юл белән таныштыру, юл билгеләре белән таныштыруны дәвам итү, шәһәр транспорт төрләренең исемнәрен ныгыту. | |
| | III | Тема: “Юл билгеләрен карау һәм рәсем ясау”. | Юл билгеләрен ныгыту, аларны кәгазъ битенә төшерү.<br>Д / уен “Светофорны җый”. | |
| | IV | Тема: “Җәмәгать транспортында үзеңне дөрес тот” | Балаларны җәмәгать транспортында үзеңне дөрес тотарга өйрәтү, бу кагыйдәләрне үтәргә теләк тәрбияләү. | |
| март | I | Тема: Д/ уен «Яшел, сары, кызыл». | Балаларны юл билгеләре һәм кагыйдәләре белән таныштыруны дәвам итү.<br>Х/ уен “Светофор”. | *Иҗади сәнгать:* рәсем «Юл һәм тротуар», ябыштыру «Минем яраткан транспорт төре».<br>*Уку:* В. Головко «Правила движения».<br>*Аралашу:*әңгәмә «Ничек машиналар кешеләргә ярдәм итәләр» |
| | II | Тема: Д / уен «Транспорт”. | Балаларны транспорт төрләре белән таныштыруны дәвам итү. Х/ уен “Машиналар һәм чыпчыклар”. | |
| | III | Тема: әңгәмә «Олы юл». | Балаларны бер һәм 2 яклы юл белән таныштыруны дәвам итү, юлда йөрү кагыйдәләрен ныгыту һәм истә калдыру. | |
| | IV | Тема: Д/ уен «Юл билгеләре» | Балалар белән юл йөрү кагыйдәләрен һәм билгеләрен ныгыту өстендә эшләү. Х/ уен “Шоферлар”. | |
| апрель | I | Тема: «Урамда ятим хайваннар» | Урамда очраган ятим хайваннар белән үз-үзеңне дәрес тоту кагыйдәләрен өйрәнү. Балалар бакчасыннан өйгә кайту юлы турында сөйләшү | *Социаль – аралашу үсеше:* сюжетлы-рольле уен «Җәяүлеләр һәм йөртүчеләр»<br>*Җыр:* күңел ачу «Балалар урманда». |
| | II | Тема: «Безнең ярдәмчеләр». | Балалар бакчасыннан өйгә кайту юлы турында белемнәрен камилләштерү. | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | Д/ уен «Сөйләшүче юл билгеләре» | *Иҗади сәнгать:* төзү «Минем урам». *Аралашу:* әңгәмә «Велосипедта йөрим». *Уку:* В. Кожевников «Светофор». *Сәдамәтлек:* әңгәмә “Заралы үсемлекләр” |
| | III | Тема: «Урманда үзеңне ничек тотарга?» | Урманда үз-үзеңне дөрес тоту кагыйдәләре белән танышу, янгын чыганакларын кисәтергә өйрәтү. | |
| | IV | Тема: «Зарарлы үсемлекләр» | «Зарарлы үсемлекләр» төшенчәсе белән таныштыру, урманда үз-үзеңне дөрес тоту кагыйдәләре турында белемнәрен ныгыту. | |
| май | I | Тема: «Юлда җәяүле». Д/ уен«Светофорны җый» | Алган белемнәрне кулланып юлда йөрү күнекмәләрен камилләштерү, светофор турында белемнәрен ныгыту | *Иҗади сәнгать: рәсем* «Мин балалар бакчасына барам»; күргәзмә оештыру «Үз кулларың белән ясалган светофор. *Физик культура:* хәрәкәтле уеннар “Төсле автомобильләр”, “Чыпчыклар һәм автомобиль” *Коммуникация: әңгәмә* “Без урамда уйныйбыз” |
| | II | Тема: «Өйгә таба юл». Д/ уен«Микрорайон буенча сәяхәт» | Микрорайон макеты буенча хәрәкәтләнү буенча белемнәрен киңәйтү. Өйгә кайту юлында тәртип кагыйдәләрен ныгыту | |
| | III | Тема: «Мин юл йөрү кагыйдәләрен беләм» | Төрле юл ситуацияләреннән чыгу юлларын өйрәтү. | |
| | IV | Тема: «Юлда үз-үзеңне тоту кагыйдәләре». *Сюжетлы – рольле уен* «Йөртүчеләр һәм җәяүлеләр» | Юл йөрү билгеләре, юлда үз-үзләрен тоту кагыйдәләре турындагы белемнәрен ныгыту | |

***Социальләштерү***

«Социальләштерү» белем бирү эшчәнлеге эчтәлеге балаларның социаль характердагы беренчел күзаллауларын үзләштерү һәм балаларны социаль мөнәсәбәтләр системасына кертү максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә нәм белем бирү бурычларын билгели.

Туган телдә аралашырга теләкләрен хуплау; башка кешеләр белән аралашканда, аларның тәкъдимнәренә әдәпле итеп җавап бирү; төрле эшчәнлек төрләрендә өлкәннәр һәм балалар белән телдән һәм телдән булмаган бәйләнешләр урнаштыру.

Әйләнә-тирә, туган шәһәр (авыл), республика вакыйгалары турында әңгәмәләрне хуплау.

Аралашу культурасы формалаштыру (сөйләшүченең милләтенә карап, ачык йөз күрсәтеп, шул телдә исәнләшү һәм саубуллашу; үтенеч һәм тәкъдимнәр белән ягымлы итеп мөрәҗәгать итү; күрсәткән хезмәте, ярдәме, сый-хөрмәте өчен рәхмәт белдерү).

Балаларны ил, республиканың күренекле төп бәйрәмнәрен билгеләп үтәргә өйрәтү. Балалар оешмасы, республика, ил тормышына баланың мөнәсәбәте, катнашы булуын аңлавына ирешү.

Өлкәннәр һәм яшьтәшләре (өч-дүрт бала) белән күмәк уеннарда катнашуга теләк уяту; әйләнә-тирәдәге тормыш, ха-лыклар яшәеше темасына татар язучылары һәм шагыйрь¬ләренең әдәби әсәрләре, мультфильмнар буенча, уен өчен катлаулы булмаган сюжетлар тәкъдим итү.

Уендагы иптәшләр арасында рольләрне бүлә белергә, уен өчен кирәкле өй кирәк-ярагы (көянтә-чиләкләр, казан, уклау һ. б.), милли костюм, ювелир (зәркән) бизәнү әйберләре, читекләр һ. б., милли уенчыклар, музыка уен кораллары сайларга һәм аларны рольгә туры китереп файдаланырга өйрәтү.

Милли киемдәге курчакларны, образлы уенчыкларны, бибабо, кулдан ясалган уенчыклар һәм кайбер сәнгатьлелек чараларын, кул хәрәкәтләре, мимика, интонация кулланып, театральләштерелгән һәм режиссер уеннарында катлаулы булмаган сюжетлар буенча (татар халык әкиятләре буенча куелган мультфильмнардан) ситуацияләрне уйнап күрсәтү.

Баланың үзе, әти-әнилөренең милләте турындагы күзаллавын формалаштыру. Гаилә рәсемнәрен караганда, әти-әниләре белән охшаш чалымнары булуына игътибар итү. Фото- сурәттәге кешеләрнең эмоциональ халәтен билгеләргә, аларның кәефләрен гаилә тормышындагы билгеле бер вакыйга белән бәйләргә өйрәтү.Гаилә турында һәм үзенең шул гаилә әгъзасы булуы турында; гаиләнең барлык әгъзаларының һәм баланың үзенең бурычлары, мавыгулары, яллары турында; гаилә гореф-гадәтләре, йолалары, бәйрәмнәренең матурлыгы һәм әһәмияте турында күзаллаулар формалаштыру. Гаилә истәлекләренә сакчыл караш тәрбияләү.

***Сюжетлы – ролле уеннар.***

***Комплекслы – тематик план***

| Ай | Атна | Эшчәнлек темасы | Эшчәнлек эчтәлеге. Бурычлар. |
| --- | --- | --- | --- |
| сентябрь | I | “Гаилә” | Әни кызын ашата, йокларга яткыра. Д./уен «Курчакны сыйлыйк», «Курчакны йокларга яткырыйк»<br>Рольләрне бүлешеп уйнарга өйрәнү, һөнәрләр һәм һөнәрләрнең эш кораллары турында белемнәрен үстерү,уйнаганда диалог коруны, татарча сөйләшүне булдыру. |
| | | “Мин сатучы” | Әни кызы белән кибеткә килә, азык-төлек ала. Сатучы товар сата, үлчәүдә үлчи.<br>Рольләрне бүлешеп уйнарга өйрәнү, һөнәрләр һәм һөнәрләрнең эш кораллары турында белемнәрен үстерү,уйнаганда диалог коруны, татарча сөйләшүне булдыру. |
| | II | “Парковка” | Юлда машиналар йөри, юл йөрү кагыйдәләрен үтеп машиналарны урыннарга куялар.<br>Рольләрне бүлешеп уйнарга өйрәнү, һөнәрләр һәм һөнәрләрнең эш кораллары турында белемнәрен үстерү,уйнаганда диалог коруны, татарча сөйләшүне булдыру. |
| | | “Коткару хезмәте” | Коткару хезмәте кешеләре авыр очракларда ярдәмгә ашыгалар: пожар, юлларда хәләкәт.<br>Рольләрне бүлешеп уйнарга өйрәнү, һөнәрләр һәм һөнәрләрнең эш кораллары турында белемнәрен үстерү,уйнаганда диалог коруны, татарча сөйләшүне булдыру. |
| | III | «Яшелчәләр кибете» | Әни кызы белән кибеткә килә, азык-төлек ала. Сатучы товар сата, үлчәүдә яшелчә үлчи.<br>Д/уен “Яшелчә кибетендәниләр сатыла”.<br>Рольләрне бүлешеп уйнарга өйрәнү, һөнәрләр һәм һөнәрләрнең эш кораллары турында белемнәрен үстерү, уйнаганда диалог коруны, татарча сөйләшүне булдыру. |
| | | «Көзге ярминкә» | Көзге ярминкәгә киләләр, яшелчә, җиләк-җимеш сатып алалар, хакларын очсызлаталар.<br>Рольләрне бүлешеп уйнарга өйрәнү, һөнәрләр һәм һөнәрләрнең эш кораллары турында белемнәрен үстерү, уйнаганда диалог коруны, татарча сөйләшүне булдыру. |
| | IV | “Даруханә” | Даруханәгә киләләр, нәрсә авыртканын әйтәләр, кирәкле дару сатып алалар.<br>Рольләрне бүлешеп уйнарга өйрәнү, һөнәрләр һәм һөнәрләрнең эш кораллары турында белемнәрен үстерү, уйнаганда диалог коруны, татарча сөйләшүне булдыру. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | «Шифаханә» | Әни кызын врачка алып килә. Врач авыруларны кабул итә, нәрсә авыртканын сорый, тыңлый, дәвалау билгели.<br>Медкабинетка экскурсия.<br>Рольләрне бүлешеп уйнарга өйрәнү, һөнәрләр һәм һөнәрләрнең эш кораллары турында белемнәрен үстерү, уйнаганда диалог коруны, татарча сөйләшүне булдыру. |
| октябрь | I | «Гаилә» | Әни юа, кием үтүкли, бүлмә җыештыра. Д./уен «Курчакның күлмәген үтүклик, бездә тәртип»<br>Рольләрне бүлешеп уйнарга өйрәнү, һөнәрләр һәм һөнәрләрнең эш кораллары турында белемнәрен үстерү, уйнаганда диалог коруны, татарча сөйләшүне булдыру. |
| | II | «Балалар бакчасы» | Балалар бакчага килә, анда музыка, физкультура белән шөгыльләнәләр.Рәсемнәр карау.<br>Рольләрне бүлешеп уйнарга өйрәнү, һөнәрләр һәм һөнәрләрнең эш кораллары турында белемнәрен үстерү, уйнаганда диалог коруны, татарча сөйләшүне булдыру. |
| | III | «Гаилә» | Әни кызын ашата, йокларга яткыра, бишек җырлары җырлый. Уку: бишек җырлары.<br>Рольләрне бүлешеп уйнарга өйрәнү, һөнәрләр һәм һөнәрләрнең эш кораллары турында белемнәрен үстерү, уйнаганда диалог коруны, татарча сөйләшүне булдыру. |
| | IV | Транспорт» | Шофёр курчакларны машинага утыртып йөртә, төзү әйберләре ташый. Әңгәмә: “Машиналар урамда ничек йөри”<br>Рольләрне бүлешеп уйнарга өйрәнү, һөнәрләр һәм һөнәрләрнең эш кораллары турында белемнәрен үстерү, уйнаганда диалог коруны, татарча сөйләшүне булдыру. |
| ноябрь | I | «Төзелеш» | Төзүчеләр машиналарга гараж төзиләр, уенчыкларга йорт, төзелеш коралларын кулланалар. Төзү материалларының детальларын карау.<br>Рольләрне бүлешеп уйнарга өйрәнү, һөнәрләр һәм һөнәрләрнең эш кораллары турында белемнәрен үстерү, уйнаганда диалог коруны, татарча сөйләшүне булдыру. |
| | II | «Йөртүчеләр һәм җәяүлеләр | Машиналар һәм җәяүлеләр юл йөрү билгеләрен үтәп эшкә баралар. Дидактик уен “Юл йөрү билгеләре”<br>Рольләрне бүлешеп уйнарга өйрәнү, һөнәрләр һәм һөнәрләрнең эш кораллары турында белемнәрен үстерү, уйнаганда диалог коруны, татарча сөйләшүне булдыру. |
| | III | «Чәчтараш» | Чәчтарашка балалар әниләре белән киләләр. Парикмахер чәч тарый һәм ала. Дидактик уен “Чәчтараш җиһазлары” |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | Рольләрне бүлешеп уйнарга өйрәнү, һөнәрләр һәм һөнәрләрнең эш кораллары турында белемнәрен үстерү, уйнаганда диалог коруны, татарча сөйләшүне булдыру. |
| | IV | «Гаилә» | Курчакның туган көне. Кунаклар чакырабыз, сыйлыйбыз.<br>Әңгәмә «Бүген кемнең туган көне?»<br>Рольләрне бүлешеп уйнарга өйрәнү, уйнаганда диалог коруны, татарча сөйләшүне булдыру. |
| декабрь | I | «Кафе» | Кафега киләләр, алар туңдырма ашыйлар, сок эчәләр. Официант заказ кабул итә һәм сораган әйберләрне китерә.<br>Дидактик уен «Без кафега килдек»<br>Рольләрне бүлешеп уйнарга өйрәнү, һөнәрләр һәм һөнәрләрнең эш кораллары турында белемнәрен үстерү, уйнаганда диалог коруны, татарча сөйләшүне булдыру. |
| | II | «Поликлиника» | Медсестра прививка ясый, витаминнар тәкъдим итә.<br>Шәфкать туташы эшен күзәтү.<br>Рольләрне бүлешеп уйнарга өйрәнү, һөнәрләр һәм һөнәрләрнең эш кораллары турында белемнәрен үстерү, уйнаганда диалог коруны, татарча сөйләшүне булдыру. |
| | III | «Транспорт» | Балалар шәһәр буйлап экскурсиягә чыгалар, бәйрәмгә бизәлгән урамнарны карыйлар.<br>Рәсемнәр карау.<br>Рольләрне бүлешеп уйнарга өйрәнүне дәвам итү, балаларны уенчыклар белән сакчыл уйнарга өндәү,балаларны иптәшләренә карата кайгыртучан, игътибарлы, ярдәмчел булырга, кешелеклелек хисләре тәрбияләү. |
| | IV | «Гаилә» | Әни кызы белән чыршы бизи, кунаклар каршы ала.Уку<br>О. Высотская «Ёлочка».<br>Дидактик уен «Акбайга кунаклар каршы алуны күрсәтик»<br>Рольләрне бүлешеп уйнарга өйрәнүне дәвам итү, балаларны уенчыклар белән сакчыл уйнарга өндәү,балаларны иптәшләренә карата кайгыртучан, игътибарлы, ярдәмчел булырга, кешелеклелек хисләре тәрбияләү. |
| | | “Театр” | Рәсемнәр карау, курчаклар карау, әңгәмә үткәрү. Балалар театрга баралар, билетлар алалар, театр күрсәтәләр. Әңгәмә “Театр төрләре”<br>Рольләрне бүлешеп уйнарга өйрәнүне дәвам итү, балаларны уенчыклар белән сакчыл уйнарга өндәү,балаларны иптәшләренә карата кайгыртучан, игътибарлы, ярдәмчел булырга, |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | кешелеклелек хисләре тәрбияләү. |
| февраль | | "Пароход" | Балалар пароходка походка чыгалар. Алдан әкиятләр, әсәрләр уку, балалар уен өчен кирәкле әйберләр җыялар.<br>Рольләрне бүлешеп уйнарга өйрәнүне дәвам итү, балаларны уенчыклар белән сакчыл уйнарга өндәү,балаларны иптәшләренә карата кайгыртучан, игътибарлы, ярдәмчел булырга, кешелеклелек хисләре тәрбияләү. |
| март | | "Зоопарк" | Балалар зоопарка баралар, билетлар алалар, хайваннарны карыйлар, ашаталар.<br>Рольләрне бүлешеп уйнау күнекмәләрен камилләштерү,балаларның дуслык турында мәгълүматларын тулыландыру, әләкләшүнең начар гадәт икәнен, дусларыңны уңайсыз хәлгә куярга ярамаганлыгын төшендерү. |
| апрель | | "Курчак театры" | Театр килде дигән афиша элеп кую. Билетлар сату,. Балалар театрга баралар, билетлар алалар, залда урыннар алалар, театр күрсәтәләр. Әңгәмә "Театр төрләре"<br>Рольләрне бүлешеп уйнау күнекмәләрен камилләштерү,балаларның дуслык турында мәгълүматларын тулыландыру, әләкләшүнең начар гадәт икәнен, дусларыңны уңайсыз хәлгә куярга ярамаганлыгын төшендерү. |
| май | | "Ашханә" | Пешекче, кондитер фотосүрәтләр карау, аларның хезмәте турында әңгәмә үткәрү.<br>Рольләрне бүлешеп уйнау күнекмәләрен ныгыту, һәнәрләрнең кирәк-яраклары турындагы белемнәрен үстерү, диалог корып сөйләшү күнекмәләрен камилләштерү. |

**«ТАНЫП БЕЛҮ ҮСЕШЕ».**

***ӘЙЛӘНӘ - ТИРӘ БЕЛӘН ТАНЫШУ.***

«Танып белү үсеше» белем бирү эшчәнлеге эчтәлеге балаларда танып белү ихтыяҗларын һәм акылны үстерү максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.

Баланы үзе яши торган урам, шәһәр (авыл), республика исемнәрен әйтергә өйрәтү. Шәһәрнең истәлекле урыннары турында сөйләү.

Туган шәһәрдә (авылда) булган вакыйгалар турында әңгәмәләрдә ешрак катнашу тәҗрибәсе туплауларына ирешү. Туган як образлары белән бәйле буклетлар, журналлар, рәсемле китаплар, альбомнар, истәлекле урыннарда гаилә белән төшкән фотосурәтләр, значоклар, открыткалар җыелмасы тупларга теләк тудыру.

Кеше яши торган торак төзелеше (шәһәрдә һәм авылда), йорт кирәк-яраклары турында күзаллаулар булдыру. Кеше кулы белән ясалган җайланмаларның төзелеше һәм билгеләнеше турында сораулар бирергә, һәр яңалык белән танышырга омтылыш тәрбияләү.

Кешенең хуҗалык эшчәнлеген - үзе, тору урыны, йорт хайваннары һәм үсемлекләр, ишегалдының, урамының чисталыгын - кайгыртуы турында беренчел күзаллаулар формалаштыру. Шәһәр (авыл) урамнарын, торак йортларны тәртиптә тотарга теләк тудыру.

Бирелгән урынның кайбер үсемлекләре: агачлар (нарат, өрәңге), бүлмә гөлләре (бальзамин, фуксия), гөмбәләр (ак гөмбә, майлы гөмбә, баллы гөмбә), җимешләр (алма, слива), яшелчәләр (кыяр, помидор, суган, кишер, шалкан), җиләкләр (кура җиләге, миләш, чия, карлыган) белән таныштыруны дәвам итү. Өлкәннәргә җиләк-җимеш, яшелчәләр уңышын җыярга булышу теләге тудыру.

Бөҗәкләр (кырмыска, умарта корты, коңгыз, шөпшә) турындагы күзаллауларын баету; кыргый һәм йорт хайваннары, төркемдәге табигать почмагында яшәүчеләр белән танышуны дәвам итү. Балалар бакчасындагы участокка очып килүче кошларны (чыпчык, кызылтүш, песнәкне) күзәтү оештыру, аларны ел буена өстәмә ашатырга теләк уяту.

Балаларның кырда, урманда, елгада күргәннәрен сөйли алуларына ирешү. Үзләренә ошаган үсемлек, хайван, табигать почмагының рәсемен ясарга, фотога төшерергә омтылыш тәрбияләү

***Комплекслы – тематик план***

| **Ай** | **Атна** | **Эшчәнлек темасы** | **Бурычлар** |
|---|---|---|---|
| сентябрь | I | “Белмәмеш байлыгы” | Предметларның төзелешен, материал үзенчәлекләрен карау, төсләре, кулланышы буенча төркемләү. |
| | II | “Балалар бакчасы” | Балаларны бакчада эшләүче хезмәткәрләр белән таныштыру, балалар бакчасының адресын, килү юлын искә төшерү. |
| | III | “Бакчада” | Яшелчәләр, җиләк – җимешләр турында белемнәрен камилләштерү, тәмен, формасын, төсен истә калдыру |
| | IV | “Аквариумда ниләр яши?” | Балыклар тормышы белән таныштыру, тышкы кыяфәтләре, төсләре турында белемнәрен камилләштерү. |
| ок | I | “Минем | Туган якка карата мәхәббәт тәрбияләү, яши торган шәһәрнед иң матур һәм күренекле |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | яраткан шәһәрем” | урыннары белән таныштыру. |
| | II | “Пыяла иләндә” | Балаларга пыяланың үзлекләрен (үтә күренмәле, ныклы, шорма) табарга ярдәм итү, куркынычсызлык кагыйдәләрен искә төшерү. |
| | III | “Бакчадагы агачлар” | Балаларны агач һәм куаклар белән таныштыру, алар арасындагы аерымлыкларны таба белергә өйрәтү, яфракларның төсен билгеләү, календарь белән эшләү рәтен аңлату. |
| | IV | “Йорт хайваннары” | Балаларны  йорт хайваннары белән таныштыруны дәвам итү, хайваннарга карата мәрүәмәтлелек тәрбияләү. |
| ноябрь | I | “Зурлар хезмәте” | Шофер хезмәте белән таныштыру, светофорның үзенчәлекләрен искә төшерү, юл йөрү билгеләрен һәм кагыйдәләрен кабатлау, зурлар хезмәтенә карата ихтирамлылык тәрбияләү. |
| | II | “Кәгазь иләндә” | Балаларга кәгазь  үзлекләрен  табарга ярдәм итү, кәгазь тарихын сөйләү, хәзерге заман кәгаз төрләре белән таныштыру. |
| | III | “Табигать почмагы” | Табигать почмагы белән таныштыру, үзлекләреннән андагы үсемлекләрне тәрбияләргә өйрәтү. Күзәтүләрне билгеләп баруны аңлату. |
| | IV | “Кышлаучы кошлар” | Кышлаучы кошларның исемнәрен атау, кыяфәтләрен истә калдыру, җим эзләгәннәрен күзәтү, аларны җим белән тәэмин итү, кошларга карата сакчыл караш тәрбияләү. Бирелгән сорауларга дөрес, ашыкмыйча, башкалар ишетерлек һәм аңларлык итеп җавап бирү күнекмәләрен үстерү. |
| декабрь | I | “Кышкы табигать» | Кышкы табигатькә хас билгеләр турындагы белемнәрен үстерү, башка ел фасыллары белән чагыштыру, матурлыкка соклану хисе уяту. |
| | II | “Безгә Айболит килде” | Табип һөнәре белән таныштыру, кеше хезмәтенә хөрмәт уяту, балалар бакчасындагы табип кабинетына экскурсия оештыру |
| | III | “Кышкы урманга сәяхәт” | Кышкы табигатькә хас билгеләр турындагы белемнәрне ныгыту,җәнлекләрнең һәм кошларның кышка ничек җайлашуы турындагы белемнәрен арттыру, кышкы урманның матурлыгын күрергә өйрәтү, табигатькә сакчыл караш һәм мәхәббәт тәрбияләү. |
| | IV | «Яңа ел | Балаларны Яңа ел бәйрәмен каршыларга әзерләү,чыршы уенчыклары белән |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | уенчыклары» | таныштыру, пыяладан ясалган уенчыкларның, предметларның билгеләрен ачыклау; бал-ның сенсор сәләтләрен һәм кызыксынуын, күзәтүчәнлеген үстерү; чыршы уенчыкларына сак караш тәрбияләү. Бәйрәмгә карата кызыксыну уяту.Яңа ел бәйрәменә серлелек өстәү. |
| январь | I | "Кыш билгеләре" | Балаларның кыш турындагы белемнәрен ныгыту; балаларның күрсәтмә образлы фикерләвен үстерү; туган табигатькә мәхәббәт һәм эстетик хисләр тәрбияләү. |
| | II | "Кар бабай" | Балаларны кышкы күренешләр турындагы күзаллауларын киңәйтү, геометрик фигураларның түгәрәкнең, өчпочмакның атамасын ныгыту, детальләрне зурлыгы буенча чагыштырырга өйрәтүне дәвам итү. |
| | III | "Җәнлекләр кышка әзерләнә" | Балаларны җәнлекләрнең кышкы табигатьтә яшәү рәвеше белән таныштыруны дәвам итү, балаларның грамматик яктан дөрес сөйләмен үстерү, балаларда тере табигатькә карата кызыксыну тәрбияләү. |
| | IV | "Җәнлекләр кышкы урманда" | Балаларның кыргый хайваннар турындагы күзаллауларын формалаштыру, табигаттәге сезонлы үзгәрешләр турындагы белемнәрен ныгыту; бәйләнешле сөйләм телен үстерү, сөйләмнең грамматик төзелешен камилләштерү; хайваннарга сакчыл караш тәрбияләү. |
| февраль | I | "Йорт хайваннары" | Йорт хайваннары турында белемнәрен камилләштерү, песине һәм этне күзәтү, үз-үзләрен тотышларын билгеләү |
| | II | "Юллар имин булсын" | Юлда үз-үзеңне дөрес тоту кагыйдәләрен кабатлау, ныгыту. |
| | III | "Без – солдатлар!" | Балаларны Ватанны саклаучылар көне б/н таныштыру; очкычның, вертлетның өлешләрен, формасын аерырга һәм атарга өйрәтүне, исемнәрне сыйфатлар белән яраклаштыру күнекмәләре формалаштыруны дәвам итү. |
| | IV | "Безнең армия" | Балаларда илне саклаучы сугышчылар турында күзаллау формалаштыру, "Ватанны саклаучылар"төшенчәсен ачыклау, хәрбиләр һөнәренә хөрмәт, патриотлык хисләре тәрбияләү. |
| март | I | "Музыка җитәкчесендә кунакта" | Балаларны әниләр бәйрәме, әниләре турындагы белемнәрен киңәйтү, музыка җитәкчесенең912 бербөтен образын тудыру, музыка коралларының төп билгеләренен ачыклау, диалоглы сөйләм формасын осталыгын үстерү. |
| | II | "Әнием | Бәйрәмнәр белән таныштыруны дәвам итү, әниләр турында тасвирлама төзү |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | турында сөйлим» | осталыгын формалаштыру, сүз байлыгын үстерү, әниләргә хөрмәт тәрбияләү. |
| | III | “Өй җиһазлары” | Балаларны өй җиһазлары белән таныштыруны дәвам итү, билгеле бер билгеләр буенча туплау. |
| | IV | “Савыт – саба” | Татар авылы көнкүреше белән таныштыру, хәзерге һәм элекке заманда кулланылган савыт – саба турындагы белемнәрен ныгыту. |
| апрель | I | “Кар бабай язны эзли” | Балаларның ел фасыллары, кыш, яз билгеләре турындагы белемнәрен ныгыту, табигать күренешләре һәм алар арасындагы бәйләнеш турындагы күзаллауларын формалаштыру. |
| | II | “Яз бүләкләре” | Балаларның яз, аның билгеләре турындагы белемнәрен ныгыту, табигать күренешләре һәм алар арасындагы бәйләнешләрне аңлатуны һәм яз көне башкарыла торган эш турындагы күзаллауларын формалаштыруны дәвам итү. |
| | III | “Яз килә, яз!” | Балаларның яз, аның айлары, билгеләре турындагы белемнәрен ныгыту, эшчәнлектә кулланган сүзләр хисабына сүзлек байлыгын активлаштыру. |
| | IV | “Татарстан байрагы” | Татарстан байрагының төсләрен ныгыту, агач һәм тукыманың билгеләрен ачыклау, кәгазъ белән эшләү алымнарын камилләштерү, Җиңү көне турында мәгълүмат бирү. |
| май | I | “Җиңү бәйрәме” | Балаларның Җиңү көне турындагы күзаллауларын формалаштыру, сугышчыларның батырлыгы турында сөйләү, кайбер хәрби һөнәрләр белән таныштыруны дәвам итү. |
| | II | “9 майны каршылап...” | Җиңү көне турында күзаллауларын формалаштыру, хәрби һөнәрләр, аларның баш киемнәре белән таныштыруны дәвам итү, хәрбиләр һөнәренә хөрмәт, горурлык хисләре тәрбияләү. |
| | III | “Чәчәкләр” | Җәйге табигаттәге үзгәрешләр, чәчәкләрнең характерлы билгеләре белән таныштыруны дәвам итү, сорауларга тулы җәенке җөмләләр белән җавап бирү осталыгын, логик, образлы фикерләүләрен, хәтерен, вак моториканы үстерү. |
| | IV | “Үрдәк бәбкәсе Бак – Бакны тасвирлау” | Уенчыкны эзлекле тасвирлап, кечкенә хикәя төзергә өйрәтүне дәвам итү, бәйләнешле сөйләм телен, игътибарларын үстерү, хикәя төзүгә кызыксыну тәрбияләү. |

**Комплексłы -тематик планлаштыру**

## НРК

| Ай | Физик үсеш ( физик тәрбия, сәламәтлек) | Социаль-шәхси үсеш (куркынычсызлык, социал-шү, хезмәт) | Танып белү, сөйләм теле үсеше (танып белү,матур әдәбият уку, коммуникация) | Сәнгати-эстетик үсеш (җыр, иҗади сәнгать) |
|---|---|---|---|---|
| Яр Чаллы, Татарстан | | | | |
| сентябрь- май | **Уеннар.**<br>«Түбәтәй» «Маэмай», «Ак куянкай», «Кояш һәм яңгыр» | **Әңгәмәләр.**<br>«С кем я живу», «О мамах и папах».<br>**Альбомнар карау**. «Моя семья», «Труд взрослых в семье».<br>Экскурсия «Хорошо у нас в саду» | **Әкиятләр.**<br>«Медведь и дед», «Кто что любит?», пер. Р.Ахмета.<br>**Поэзия.**<br>А. Ерикеев «Осень наступила...» , пер Л. Гинзбурга; М. Джалиль «Кукушка»; «Мой пес»; Г.Тукай «Наша семья», «Когда это бывает?».<br>**Проза.**<br>А. Алиш «Два петуха»<br>**Яттан өйрәнү өчен**<br>«Этот палец- дедушка…», Р. Миннуллин «Кар ява». | **Җыр.**<br>«Баю-баюшки…», пер. Э. Каюмовой; « Ворона прилетела..» пер. Р. Ягафарова; «Большие ножки шли по дорожке...», пер. А. Аминова; «Дождик, дождик, лей, лей...»; «Ворона каркает: кар-карр..», пер. Р. Ягафарова.<br>Хоровод «Күрсәт әле үскәнем», «Әпипә».<br>Наблюдение за проведением праздников.<br>**Сәнгати үсеш**<br>**Әвәләү.**<br>Тарелка, пиала.<br>**Аппликация.**<br>«Красивая тарелка»<br>**Рәсем ясау.**<br>«Узор на платке» (салфетке)<br>**Бәйрәмнәр.**<br>«Сөмбелә», «Нардуган», «Нәүрүз», «Сабантуй» |
| **Россия** | | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Ноябрь - Апрель | **Уеннар.**<br>«Кот и мыши», «Воробушки и кот», «Наседка и цыплята», «Кролики», «Солнышко и дождик», «Воробушки и автомобиль» | **Әңгәмәләр.**<br>«Что делать если потерялся», «Машины на нашей улице» | **Әкиятләр.**<br>«Теремок», «Маша и медведь»<br>**Поэзия.**<br>А. Барто «Игрушки», К. Чуковский «Муха – цокотуха», «Айболит», «Мойдодыр»<br>**Проза.**<br>Л. Толстой «Была у Насти кукла», «Был у Пети и Миши конь», В.Берестов «Большая кукла»<br>**Яттан өйрәнү өчен.**<br>Пальчик-мальчик, Заинька попляши, Сорока-сорока | **Җыр.**<br>**Песенки, потешки, заклички.**<br>«Петушок», «Ладушки», «Зайчик»<br>**ИЗО деятельность.**<br>**Әвәләү.**<br>«»Неваляшка», «Цыпленок», «Яблоки лежат на тарелке»<br>**Аппликация.**<br>«Украсим Маше сарафан»<br>**Рәсем ясау.**<br>«Моя любимая игрушка», «Здравствуй, солнышко», «Снег кружится», «Дождик»<br>**Бәйрәмнәр.**<br>«Рождество», «Масленица» |

***Матур әдәбият белән танышу.***

«Матур әдәбият уку» белем бирү эшчәнлеге эчтәлеге балаларда китап укуга кызыксыну һәм ихтыяҗ формалаштыру максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.

Әдәби әсәрләрнең төрле жанр һәм тематикасын - халык әкияте, татар язучылары һәм шагыйрьләренең хикәя, шигырьләрен, шигъри фольклорның кече формаларын тыңлау, аларның эчтәлегенә хисләрен белдерү сәләтен үстерү.

Әкият геройлары һәм аларның характерлары, чынбарлыкта булган хәлләр, балалар һәм өлкәннәр эшләгән эшләр турындагы күзаллаулар ярдәмендә баланың эчке дөньясын баету, укыганны аңлар өчен сораулар бирү һәм фикер алышу.Тәрбияче ярдәмендә татар әкиятләреннән өзекләрне сәхнәләштерергә өйрәтү.Укыган әсәрдән аеруча кызыклы, сәнгатьле өзекләрне кабатлаганда, балаларга сүзләрне һәм катлаулы булмаган фразаларны әйтеп бетерергә мөмкинлек бирү.Кечкенә күләмле шигырьләрне, шигъри фольклорның кече формаларын яттан сөйләүләрен хуплау.  Уен һәм сәнгать эшчәнлекләрен, конструкцияләү һ. б. ны әдәби образлар белән баету.

***Комплекслы – тематик план***

| Ай | Атна | Эшчәнлек темасы | Бурычлар |
|---|---|---|---|
| сентябрь | I | Хәкимҗан Халиков “Көз” шигыре | Шигырьне тынлый белергә өйрәтү, эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирү,сөйләм телен үстерү, көз ел фасылындагы матурлыкка соклану булдыру |
| | II | Зәкия Туфайлова “Шофер булам” шигыре | Шигырьне тынлый белергә өйрәтү, сорауларга җавап бирү, сөйләм телен үстерү,шофер хезмәтенә хөрмәт уяту |
| | III | Фәнис Яруллин “Көзге табын” шигыре | Шигырьне тынлый белергә өйрәтү, сорауларга җавап бирү, сөйләм телен үстерү, көз ел фасылындагы матурлыкка, мул уңышка соклану булдыру |
| | IV | Әхәт Гаффар “Суалчан кунакка бара” әкияте | Әкиятнене тынлый белергә өйрәтү, эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирү,сөйләм телен үстерү, җитез булырга өндәү |
| октябрь | I | Ш.Галиевның “Дәү әнигә күчтәнәч” шигырен ятлау. | Дәү әниләргә карата хөрмәт хисләре тәрбияләү; балаларның хәтер сәләтен, игътибарлылыгын үстерү, шигырьне сәнгатьле итеп сөйләү күнекмәләре бирү. |
| | II | “Без әкият яратабыз” | Рәсемнәр буенча әкиятләрне искә төшерә, истә калган әкиятләрне өстәл теетры белән күрсәтү |
| | III | Ә.Ерикәй”Чисталык сөябез(ятлау) | Шигырь аша бал-да чисталыкка омтылыш тәрбияләү;эзлекле һәм сәнгатьле итеп шигырьне сөйләү күнекмәләрен, хәтер сәләтен үстерү; балаларны гигиена кагыйдәләренә гадәтләндерергә өйрәтү, чисталык-сәламәтлекнең нигезе икәнен төшендерү |
| | IV | А.Алиш “Чукмар белән Тукмар” | Шушы әкият белән балаларны таныштыру, эчтәлегенә, мәгънәсенә төшенергә ярдәм итү, балаларга дуслык, татулык турында аңлату, авазларны дөрес итеп әйтергә, аларны кушып төрле сүзләр уйларга ярдәм итү |
| ноябрь | I | “Мин яратам сине, Татарстан!” Р.Рәкыйпов. | Матур әдәбият әсәрләре аша балалар күңелендә туган илне сөю хисе тәрбияләү; бал-ның тыңлый белү, үз фикерләрен башкаларга җиткерә белү сәләтен үстерү; туган як турында балаларның белемнәрен системалаштыру; сорауларга тулы җавап бирүләренә ирешү. |
| | II | “Туган илнең улы мин”, Р.Миңнуллин. | Р.Миңнуллинның китаплары,шигырьләре белән танышу. |
| | III | “Әләкче бүре» әкияте | Әкият белән танышу, начар һәм матур гадәтләр турында белемнәрен киңәйтү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | Әләкләшүнеә начар гадәт икәнен аңлату. |
| | IV | М.Гафури «Әби белән онык» | Өлкәннәргә хөрмәт хисе, ихтирамлылык тәрбияләү, аларга ярдәмчел булырга өйрәтү, өлкәннәргә булышу теләге тәрбияләү. |
| декабрь | I | Ә.Бикчәнтәева “Минем әнием” | Шигырьне уку, өйрәтү; әнигә карата балаларда ихтирам тәрбияләү, ярдәм итәргә теләк уяту. |
| | II | К.Ушинский “Кыш әбинең шуклыгы”. | Серле табигать күренешләренә соклану хисләре һәм мәхәббәт уяту; балаларның фикерләрен бер юнәлештә туплый белү сәләтен үстерү; кышкы салкын көннәрнең кошлар, хайваннар, кешеләр өчен авыр вакыт булуын ачыклау. |
| | III | Ә.Кари “Кошлар туйдырам”. | Кошларның кышкы тормышлары турында балаларга сөйләү, аларга карата кызгану хисе уяту, ярдәм итәргә теләк тудыру.Шигырьнең эчтәлеге белән таныштыру. Җ авазы өстендә эш. |
| | IV | М.Фәйзуллина “Кыш бабай” шигырен ятлау. | Балаларның хәтерен, сәнгатьле сөйләмен үстерү, Кыш бабай образын күзаллауны үстерү, бәйрәмнәргә карата кызыксыну тәрбияләү. |
| гыйнвар | I | Хәйдәрнең “Керпе туны” экиятенең эчтәлеген сөйләү. | Балал әсәрнең эчтәлеге белән таныштыру, сорауларга дөрес җавап бирү осталыгын камилләштерү, эчтәлеген аңларга, сәнгатьле һәм бәйләнешле итеп сөйләргә өйрәтү. |
| | II | Г.Толымбай “Буран” | Табигать күренешләренә соклану хисләре тәрбияләү, шигырләрнең эчтәлеген аңлап, сорауларга тулы җавап бирүләренә ирешү, сәнгатле сөйләмгә өйрәтү. |
| | III | Н.Мадьяров “Шуабыз» | Шигырьне укып эчтәлеген аңлау. “Ш” авазы өстендә эш. |
| | IV | Җ.Тәрҗеманов “Кыш” | Серле табигать күренешләренә соклану хисләре һәм мәхәббәт уяту; бал-ның фикерләрен бер юнәлештә туплый белү сәләтен үстерү; сәнгатьле сөйләмгә өйрәтү. |
| февраль | I | “Алпамыш шәһәргә килде”. | Юлда үз иминлеген һәм башкаларның иминлеген кайгыртусыйфаты тәрбияләү; логик фикерләү сәләтен үстерү; матур әдәбият аша балаларның юл йөрү кагыйдәләре турындагы белемнәрен тирәнәйтү һәм ныгыту. |
| | II | Ш.Галиев “Светофорның өч күзе” | Шигырь аша светофор турындагы белемнәрен ныгыту,хәтер сәләтен үстерү;шигырьне яттан сәнгатьле сөйләргә өйрәтү, регулировщик турында кыскача белем бирү. |
| | III | К.Булатова “Солдатлар” | Илебезнең тынычлыгын саклаучы солдатларга карата патриотик хисләр |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | тәрбияләү, хәтер сәләтен үстерү, эчтәлек буенча сорауларга төгәл, аңлаешлы итеп җавап бирергә өйрәтү. |
| | IV | “Карт белән Төлке” (татар халык әкияте) | Балаларга әкиятне уку, фикерләү сәләтен үстерү, әкиятнең мәгънәсен аңларга ярдәм итү. |
| март | I | Д. Хәбибуллинаның “Бүләк” шигырен уку. | Хатын – кызлар бәйрәме турында белемнәрен тирәнәйтү, шигырь текстын тыңларга һәм эчтәлеген аңларга өйрәтүне дәвам итү. |
| | II | Ә.Бикчәнтәева “Минем әнием” | Шигырь белән таныштыру. Әниләргә карата балаларда ихтирам тәрбияләү. |
| | III | “Кошлар рәхмәте” Әхсән Баян. | Балаларның кошлар турындагы белемнәрен арттыру.Шигырьне тыңлау, эчтәлеген аңлау, сөйләп карау. |
| | IV | “Без әкият яратабыз” | Халык авыз иҗаты – әкиятләр белән таныштыруны дәвам итү, магнитның металлдан ясалган предметларны тарту көче белән таныштыру. |
| апрель | I | Б.Рәхмәтнең «Яз» шигыре (ятлау) | Табигатьнең матурлыгын күрә, аңа соклана белү хисләре тәрбияләү. Сәнгатьле сөйли белү осталыкларын үстерү.Аерым сүзләрне аңларга булышу, татар теленә генә хас авазлар кергән сүзләрне дөрес әйтүләренә ирешү. |
| | II | К. Ушинскийның “Хайваннар бәхәсе” әсәрен уку. | Балаларның сорауларга җавап бирү осталыгын ныгыту, сюжетның эзлекләрен истә калдырырга ярдәм итү, әсәрне игътибар белән аңлап тыңларга өйрәтүне дәвам итү. |
| | III | Сәхнәләштерү. Г.Тукай “Бала белән күбәләк”. | Г.Тукай әсәрләренә кызыксыну уяту;бал-да оештыру һәм алып баручы ролен башкару осталыгын формалаштыру,уенны алып баручы һәм башка катнашучыларның гамәлләренә яраклаштырырга өйрәтү. |
| | IV | Ә. Рәшитнең “Кояшлы ил” шигырен яттан өйрәнү. | Балаларга шигырнең эчтәлеген аңларга булышу, сәнгатьле итеп сөйләргә өйрәтү, кайбер сүзләрнең мәгънәсен аңлату, сорауларга тулы фразалар белән җавап бирү осталыгын үстерү. |
| май | I | С.Шакир. Бабамның медальләре. | Ватанга мәхәббәт тәрбияләү. Шигырь аша Бөек Ватан сугышы геройлары турында күзаллауларын киңәйтү. |
| | II | Р. Миңнуллин “Туган илнең улы мин” | Шигырьне укып эчтәлеген аңлау, тыныч туган ил булдыру турында сөйләшү, туган якка мәхәббәт тәрбияләү |
| | III | “Тавык, Тычкан, | Балаларга әкиятнең эчтәлеген аңларга булышу, персонажларның гамәлләрен |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Көртлек” татар халык әкиятен сөйләү | анализлау сәләтен формалаштыру, сорауларга тулы фразалар белән җавап бирү осталыгын үстерү. |
| | IV | “Күбәләкләр ничек килеп чыккан?” филиппин халык әкиятен уку | Әкиятнең эчтәлеген кабул итәргә һәм аңларга өйрәтү, җәй турындагы белемнәрен ныгыту, әкиятләр белән кызыксыну, чәчәкләргә, күбәләкләргә сакчыл караш тәрбияләү. |

**«ИҖАДИ - ЭСТЕТИК ҮСЕШ» белем бирү өлкәсе.**

***СӘНГАТЬ ИҖАТЫ.***

«Иҗади сәнгать» белем бирү эшчәнлеге эчтәлеге балаларда әйләнә-тирәдәге матурлыкка кызыксыну уятуны һәмүз- үзләрен күрсәтү ихтыяҗларын канәгатьләндерүне формалаштыру максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә ҺӘМ белем бирү бурычларын билгели.

***Рәсем ясау.***

Балаларның игътибарын табигать матурлыгына юнәлдерү, алар белән берлектә үсемлек һәм хайваннар дөньясы объектларының форма, төс, төзелеш камиллегенә соклану.

Татар декоратив-гамәли сәнгате әсәрләре белән танышуны дәвам итү.

Бер, ике яки берничә төсне кулланып, гади элементлардан торган тасма (бордюр) бизәге ясый белүне формалаштыру. Чәчәкле үсемлекләргә төсләрне туры китерү кирәклегенә игътибар итү.

Берничә өлештән (кош, күбәләк, умарта корты фигуралары) торган предметларның формасын һәм төзелешен чагылдырырга өйрәтү.

Төсмерләр (зәңгәрсу, соры, алсу, шәмәхә) белән таныштыру, төсләрне тою хисен үстерү.

Татар декоратив-гамәли сәнгате үрнәкләре буенча күмәк эшләрне үтәүгә тарту.

Туган шәһәр (авыл) тормышыннан матур вакыйгаларны рәсемгә төшерергә теләк уяту. Рәсемнәрне бергәләп карау һәм нәрсә ясаганны сөйләүләренә ирешү. Иҗади активлык тудырырга булышу.

***Комплекслы – тематик план***

| **Ай** | **Атна** | **Эшчәнлек темасы** | **Бурычлар** |
|---|---|---|---|
| с е | I | Рәсем: «Яңгыр» | •Балаларны традицион булмаган рәсем ясау (бармак белән) техникасы белән таныштыру. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | •Штрих, буяуларны салмак төшерергә өйрәтү. Рәсем ясау шөгыленә кызыксыну уяту |
| | II | Рәсем: «Тылсымлы таякчык» | •Балаларны карандаш (флома-стер) белән таныштыру һәм алар белән кулланырга өйрәтү, рәсем ясау барышына һәм нәтиҗәсенә кызыксыну уяту.Балаларны тыңларга һәм гади күнекмәләрне эшләргә өйрәтү. Балаларны төс һәм форма белән таныштыруны дәвам итү. •Балаларны рус шагыйре Н.В. Беловның «Карандаш» дигән ши-гыре белән таныштыру |
| | III | Рәсем: «Сукмак буйлап» | •Төрле зурлыктагы эзләрне та-ныргa һәм тимгел-темгел таплар-ны ритмик рәвештә төшерергә өйрәтү.Балаларда пумаланы дөрес тотарга, пумала белән эшләү тех-никасын өйрәтүне ныгыту. Балаларда пөхтәлек тәрбияләү. |
| | lV | Рәсем: «Тесле тасмалар», «Филимонов уенчыгы» | Төрле юнәлештәге туры сызыклар үткәрергә, предметка туры килгән төсне сайлап алырга өйрәтү. Пумала белән сызыклар-ны өстән аска таба юнәлтергә (сулдан уңга). •Пумала юу осталыгын ныгыту, пумала белән пөхтә куллана белергә өйрәтү. •Балаларда төс һәм ритмны үстерү.Балаларда уенчыкларга карата сакчыл караш уяту. |
| октябрь | I | Рәсем: «Курчакның итәген бизибез» | •Түгәрәк формадагы предмет-ларны ясарга өйрәтү, рәсем барышында турле төстәге каран-дашлар куллану.Төсләрне аера белергә өйрәтү, (кызыл, сары, яшел, зәңгәр) Рәсемне альбом битендә дөрес урнаштырырга өйрәтү.Балаларда төрле халык, мәдәниятына сәнгатенә соклану хисе тәрбияләү. |
| | II | Рәсем: «Туплар тәгәриләр» | •Балаларда рәсем ясарга кызык-сыну уяту.Балаларда төс һәм ритм хисен үстерүне дәвам итү. Ярдәмчеллек тәрбияләү. Ә. Бикчәнтәеваның «Туп-туп ту-бызыз» шигырен искә төшерү. |
| | III | Рәсем: «Аю баласына бизәкле чынаяк» | •Декоратив эшчәнлеккә тарту, савыт силуэтын төрле бизәкләр белән бизәргә өйрәтү.Түгәрәк формалы предметлар-ны бертуктаусыз хәрәкәт белән ясарга һәм сурәтне буярга. Битне рәсемнәр белән тутыру осталыгын арттыру. «Өч аю» әкиятен искә төшерү. |
| | lV | Рәсем: «Көзге яфраклар», «Көз» | •Сызык, штрих, буялыш (мазки), тимгел-тимгел тапларны ритмик рәвештә төшерергә, пумаланы буяулы банкага пөхтә итеп манар-га, артык буяуны банка кырыена ышкып төшерергә, башка төсне манганчы, пумаланы юарга. Юыл-ган пумаланы йомшак чүпрәк яки кәгазь салфеткага сөртеп киптерергә гадәтләндерү. Төс исемнәрен белүләрен ныгы-ту (кызыл, сары).Эстетик тәрбия бирү: абигатьнең матурлыгына игьтибар иттерү.Ә. Ерикейның «Көз» шигыре белән таныштыру. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| ноябрь | I | Рәсем: «Күңелле түгәрәкләр» | • Рәсәмнәң өчтәләгән алдан уйлап ясау ниятен ахырына кадәр җиткерергә, әйберләрне форма буенча билгеләргә өйрәтергә. Түгәрәк формадагы предметларны һәм күренешләрне сурәтләргә өйрәтү. Төс исемнәрен белүләрен ныгыту (кызыл, яшель, зәңгәр). Балаларның активлыгын һәм иҗат иркенлеген арттыру. Рәсем ясауга кызыксыну уяту. |
| | II | Рәсем: «Тимер юлы» | •Балаларга гади предметларны ясарга өйрәтү.<br>•Туры сызыклар ясау һәм аларны кисештерү алымнарын ныгыту (вертикаль, горизанталь).Кулларның дөрес йөрешен координацияләү. |
| | III | Рәсем: «Агач үсте» | •Балаларда агач ясарга кызык-сыну уяту. Туры сызыклардан тора торган гади предметлар ясау күнекмәләрен ныгыту.Балаларның сүзлек байлыгын арттыру: кәүсә — биек, озын, тигез; ботак — нәзек; агачлар — зур, кечкенә.<br>Балаларны эстетик яктан тәрбияләү: балаларның игътибарын туган ик табигатенең гүзәллегенә юнәлтү. Туган як табигатенә сакчыл караш тәрбияләү. |
| | lV | Рәсем: «Кар, кар ява» | •Сызык, штрих, буялыш (мазки), тимгел-тимгел тапларны ритмик рәвештә төшерергә өйрәтү, тау сүрәтен төшергәндә авыш сызыклар куллануны дәвам итергә.Балаларны кагазь битендә ори-ентлашырга өйрәтү: кар ява - өстән аска, җирдә (аста) — тау. Балаларда төс хисен үстерү, исемнәрен ныгыту.<br>•Балаларны эстетик яктан тәрбия-ләү: балаларның игътибарын туган як табигатенең гүзәллегенә юнәлтү. Туган як табигатенә сакчыл караш тәрбияләүне дәвам итү. Татар шагыйре Р. Миңнуллин «Кар ява» шигыре белән таныштыру. |
| декабрь | I | Рәсем: «Кыш» | •Сызыклы буялыш (мазки), рит-мик рәвештә төшерергә өйрәтү.<br>•Балаларга таныш булган пред-метларны ясауны ныгыту(агач, скамейка, горка)<br>•Эстетик тәрбияне үстерү: тирә-як табигатькә сакчыл караш |
| | II | Рәсем: « Бизәлгән чыршы» | •Халыкара Яңа ел бәйрәменә карата балалар күнелендә кызык-сыну уяту. Чыршының ботакла-рын дөрес юнәлештә күрсәтергә өйрәтү.<br>•Композиция күнегүнәрен ныгы-тырга (сурәтне үзәктә урнашты-рырга» сүрәт зурлыгын кәгазь бите белен чагыштырып рәсем ясарга). Балалар күңелендә матур» бизәлгән чыршы ясарага кызык-сыну уяту. М. Красева көенә, З. Александро-ва сузләре «Маленькая елочка» җырын искә төшерү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | III | Рәсем: «Минем бияляем» | •Яңа рәсем ясау техникасы белән таныштыру (бөке белен кулла-нып).Бөтен өслекне түгәрәкләр яисә буйчыклар белән тутырырга өйрәтергә.Җылы, йомшак, уң-сул төшенчәләрен ныгыту. В. Лифшицның «Рукавички» ши-гыре белән таныштыру. |
| | lV | Рәсем: «Чыршы урманда үсә» | •Музыкаль әсәр буенча гади сюҗетлы, төрле зурлыктагы рәсемнәр ясарга өйрәтү.Бармаклар белән ясау күнекмәсен ныгыту.Балаларның активлыгын, иҗат иркенлеген арттыру. Беманның «В лесу родилась ёлоч-ка» җырын искә төшерү. |
| гыйнвар | I | Рәсем: «Күңеле төшмәс курчак» | •Түгәрәк формадан торган предметлар ясарга өйрәтү. Композиция күнекмәләрен, предметларны кагазь битенең уртасына урнаштырыга өйрәтү.Рәсемне тулылындырырга өйрәтү. Балаларда төс (кызыл, сары, зәң-гәр, яшел), форма (тугәрәк) һәм зурлык, урнаштыру (астан, өстән, яннар буйлап, уртада) белемнәрен үстерүне дәвам итү.Балаларның активлыгын һәм иҗат иркенлеген арттыру. П. Энтинаның «Ванька встанька» музыкаль язмасын тыңлату |
| | II | Рәсем: «Кышкы ак көн» | •Чынбарлыктагы күренешләрне контраст төсләр кулланып тасвирларга өйрәтү. •Бер сюҗетта берничә предметны куллануны ныгыту(агач, скәмия,юл, әзләр) •Рус шагыйре И. Суриковның ширырен файдаланып туган як табигатенә соклану хисе уяту. |
| февраль | I | Рәсем «Куянны рәнҗеттеләр» | •Балаларга куян рәсеме ясарга өйрәтү. Рәсем ясау барышында аның пропорциясен саклауны ныгыту (гәүдә - зур, баш - кечерәк, койрык - кечкенә, колоак - озын) •Куян образын сурәтләргә һәм кәгазь битенә урнаштырырга өйрәтү. •Табигат белән кызыксыну һәм аны ярату хисләре формалаштыру. Балаларны Р. Корбан «Куянны рәнҗеттеләр» дигән шигере белән таныштыру |
| | II | Рәсем: «Дымка уенчыклары» | •Балаларда төрле халыклар мәдәниятына, сәнгатенә соклану хисе тәрбияләү •Балаларны рус халык уенчы-клары белән таныштыруны дәвам итү. Уенчыкларга карата соклану хисе уяту.Дымка уенчыкларын бизәргә өйрәтү, (нокталар, түгәрәкләр, боҗралар)Карандашлар белән эшләүне ныгыту, (акбур, фломастер) •Төс хисен уяту. |
| | III | Рәсем: «Әтигә матур чәчәкләр» | •Рәсемне төрле алымнар кул-ланып эшләргә өйрәтү, (төшерү, ясау) Рәсемне тулыландырырга өйрәтү.Композицияләү хисен үстерү.Якыннарына карата җылы хисләр уяту. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | IV | Рәсем: «Кояш, кояш, кояш, чык» | •Нурлары төрле якка таралган кояш рәсеме ясарга өйрәтү.Сүзлек байлыгын арттыру. Предметларның сызык аша конту-рын билгеләргә өйрәтү. •Рәсемне тулылындырырга өйрәтүне дәвам итү. Төсләрне, форманы белүләрен ныгыту.Балаларның активлыгын һәм иҗат иркенлеген арттыру. •Татар халык уены «кояш чык» белән таныштыру. |
| март | I | Рәсем: «Яз килде» | •Буялыш (мазки), тимгел-тап-ларны ритмик рәвештә төшерергә өйрәтүне дәвам итү. Композиция күнекмәләрен үстерү. Астан өскә, өстә, аста төшенчәләрен формалаштыру.Эстетик тәрбия бирү: туган җир табигатнең матурлыгына уңай эмо-циональ караш тәрбияләү.Табигать күренеше - язгы тамчы, балаларда зур кызыксыну уяту» Балаларны Әхмәт Ерикәйнең «Тышта яз» дигән шигере белән та-ныштыру |
| | II | Рәсем: «Болында тузганаклар» | •Сюҗетлы рәсем ясарга кызык-сыну уяту. Рәсемне кәгез битендә дөрес итеп урнаштыруны дәвам итү.Табигать почмагының матурлы-гын күрә белергә өйрәтү. Бала-ларда туган якка, үсемлекләр дөньясына карата мәхәббәт хисе тәрбияләү. •Рәсем ясау дәресләренә кызык-сыну уяту. Балаларны тыңларга һәм гади күнекмәләрне эшләргә өйрәтү.О. Высотскойның «Одуванчик» шигыре белән таныштыру. |
| | III | Рәсем: «Куянга булышабыз» | • Балаларны дүртпочмаклар ясарга өйрәтү. Буяу ысулларны кабатлау. Пөхтә эш күнекмәләрен формалаштыру.Дүрт почмакның озын, кыска яклары һәм почмак тәшенчаләрен формалаштыру. Төсләрне белүләрен ныгыту.Рәсем ясау шөгыленә кызыксыну уяту. искә төшерү.Рус халык әкияте «Заюшкина избушка» ны искә төшерү. |
| | IV | Рәсем: «Матур әләм» | •Тоташ сызык белән турыпочма-клык ясарга өйрәтү.Турыапочмак формасын буярга өйрәтүне дәвам итү.Балаларда төс һәм форма хисен үстерү. Нәтиҗәгә кызыксыну тәрбияләргә |
| апрель | I | Рәсем «Уенчыклар арбасы» | • Кулны биттән алмый гына, турыпочмаклык ясарга өйрәтү. Буяулар белән эшләү ысулларны ныгыту.Пумаланы буяуга дөрес итеп манарга өйрәтү. Пумаланы буяуга пөхтә итеп манарга, артык буяуны банка кырыена ышкып төшерергә, башка төсне манчыганчы пума-ланы юарга. Рәсемне тулылан-дырырга өйрәтү, уенчыкларга |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | сакчыл мөнәсәбәт тәрбияләү |
| | II | I Рәсем: «Әкиятләрдән таныш хайваннар» | •Балаларга рәсемнәрдә әйләнә-тирәдәге предметларның һәм табигатнең матурлыгын сурәтләп бирергә тәкъдим итү, каты кыллы пумала белән төртү техникасын күнектерү.Төс һәм предметны туры ките-рергә өйрәтү.<br>•Балаларга таныш булган хай-ваннар катнашындагы әкиятләрне искә төшерү. |
| | III | Рәсем: «Могҗиза-агачы» (Күмәк эш) | •Балаларны бергә эшләргә өйрәтү.Балаларга таныш булган пред-метларны ясату. • Балаларның уй-хыялларын ныгыту. К.И. Чуковскийның "Чудо-дерево" әсәрен искә төшерү. |
| | IV | Рәсем: «Чебиләр» | •Балаларга таныш булган пред-метларны мөстәкыйль ясарга өйрәтү.Пропорция саклап рәсем ясарга өйрәтүне дәвам итү.«Чебиләр» ял минутын искә төшерү. |
| май | I | Рәсем: «Мимоза чәчәге» | •Бармак белән ясау техникасын ныгыту.Төс исемнәрен белүләрен ны-гыту, төсмерләр белән таныш-тыру. Сурәтләнүче предметка туры килгән төсне сайлап алырга өйрәтү.Үз эшләренә нәтиҗә ясату. |
| | II | Рәсем «Камка» («Божьи коров-ки на лужай-ке») | •Балалрга рәсем ясау барышында төрле алымнар кулланырга өйрәтү (пумала белен ясау, печать)Балаларны төсләр белән таныш-тыруны дәвам итү.<br>Табигатькә карата кызыксыну уяту һәм үз иҗатларында чагылдыру. |
| | III | Рәсем: «Җәй, җәй, җәй килә» | •Балаларга таныш булган предметлардан сюжет берләштерергә өйрәтүне давам итү.<br>•Карандаш белән рәсем ясау техникасын ныгыту (акбур, фломастер)<br>•Балаларны табигатьне яратырга өндәү. |
| | IV | Рәсем: «Сабантуйга яулык» | •Форманы үзең теләгәнчә бизәргә өйрәтү.Балаларга рәсемне кәгазь биттә дөрес итеп урнаштыруны искә төшерергә (уртада, почмакларда, бөтен бит буйлап). Балаларны төрле халык гореф-гадәтләренә күнектерү.Халык бәйрәмнәренә кызыксыну уяту. |

***Кисеп – ябыштыру.***

Кисеп ябыштыру сәнгатенә кызыксыну уяту, аның эчтәлеген катлауландыра һәм төрле сурәтләү мөмкинлекләрен киңәйтә бару.

Тәрбияче әзерләп биргән бертөрле, төрле формадагы һәм зурлыктагы 2-3 кисәктән торган предметларның сурәтләрен кәгазь битенә тезеп чыгарга һәм ябыш-тырырга өйрәтү Ритм-тоемлау хисен уяту.Бер бит кәгазьдә берничә предметны ябыштыру юлы белән (урам, шәһәр), балаларны сюжетлы аппликация төзүгә якын китерү. Пөхтә эшләү күнекмәләре булдыру.

Татар декоратив-гамәли сәнгатенең үрнәкләре буенча әзер формалардан (чәчәкләр, күбәләкләр, кошлар) коллектив композиция төзегәндә, үзара ярдәмләшеп эшләү теләге уяту.

**_Комплексλы – тематик план_**

| | | | |
|---|---|---|---|
| ***Кисеп – ябыштыру.*** сентябрь | II | «Чебиләр очен койма» | •Тәрбияче әзерләп биргән бертөрле, төрле формадагы һәм зурлыктагы 2-3 кисәктән торган предметларның сурәтләрен кәгазь битенә тезеп чыгарга һәм ябыш-тырырга өйрәтү. •Җилемне пумалага кирәк кадәр генә алырга, әзер формаларга җилемне клеенка өстендә сы-ларга, чүпрәктән файдаланырга өйрәтү.Балаларда мөмкин кадәр пөстә эшләү теләген үстерү. •Балаларны «Төлке һәм тавык » уены белән таныштыру. |
| | IV | «Парк сукма-кларында керпе эзләре» | •Балаларга яфракларны төсләренә карап аралаштырып куярга өйрәтү.Җилемне пумалага кирәк кадәр генә алырга, әзер формаларга җилемне клеенка өстендә сыларга, чүпрәктән файдаланырга өйрәтү.Балаларда туган якларына мәхәббәт, ачык матур күренешләргә кызыксыну уяту. |
| октябрь | II | «Әминәгә ярдәм итәбез» | •Төрле төстәге түгәрәкләрне кәгазьгә таратып салырга өйрәтү. •Балаларда ритм һәм төс хисен үстерү. Балаларда ярдәмчеллелек, пөхтәлек тәрбияләүне дәвам итү. Ә. Бикчәнтаеваның «Туп» шигы-рен искә төшерү. |
| | IV | «Миләш мәрҗәне» | •Түгәрәк сәйләннәрне сызылган сызыкка пөхтә итеп урнаштыру.Балаларда эстетик караш тәрбияләүне дәвам итү.Эш барышында пөхтәлеккә өндәү.Туган як халкынын мәдәнияты белән таныштыруны дәвам итү. |
| ноябрь | II | «Акбайга җылы келәм» | •Геометрик фигураларны һәм та-бигый материалларны форма һәм төсләре буенча чиратлаштырырга өйрәтү. Балаларда ритм һәм төс хисен үстерү. Буй, төс исемнәрен (кы-зыл, сары) һәм киңлектә урынны билгеләү осталыгын ныгыту. Җилем белән пөхтә эш итергә йөрәтү. Тәрбиячене тыңларга, эшне нәтиҗәле үтергә осталыкны тәрбияләү. Хайваннарга сакчыл караш тәрбияләү. |
| | IV | «Матур шарлар» | •Әзер формаларны төс буенча чиратлаштырып ябыштыруны кунектерергә.Җилем белән эшләүне автомат-лаштыру.Төс (кызыл, сары, зәңгәр, яшел) һәм ритм хисен үстрерү. Балалар-да күмәк эшнең нәтиҗәсен күрүдән шатлык хисе уяту. |
| декаб рь | II | «Кар бабай һәм чыршы» | •Балаларга берничә кисәктән торган сурәтләр ясарга өйрәтү.Геометрик фигураларны, төсләрне, формаларын аерырга өйрәтүне дәвам итү.Предметларның охшаш якла-рын табарга өйрәтү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | IV | «Бәйрәм үремнәре» | •Әзер кәгазь буйчыгына компо-зицияне һәм төсләрне уйлап әзер формаларны ябыштыру (шарчы-клар, сәйләнләр, шапылдаткачла.Кисеп ябыштыру күнекмәләрен ныгыту.Төс һәм ритм хисен үстерү. Балаларны тыңларга һәм гади күнекмәләрне эшләргә өйрәтү. Эш барышында балаларда сабырлык, пөхтәлек хисен тәрбияләү. •Балаларда күмәк эшнең нәтиҗәсен күрүдән шатлак хисе уяту, шатлык хисләре, бәйрәм рухын булдыру. |
| январь | II | «Матур тастымал» | •Балаларны кәгазь битендә шак-мак формасындагы бизәк ясарга, бит почмакларына, бертөсле зур түгәрәкләр урнаштырырга, алар өстенә кечкенә икенче төстәге түгәрәкләр куерга өйрәтергә. Композиция төзү күнекмәсен дәвам итү, төсләрне чагыштырырга өйрәтү.Эстетик тәрбия бирү: башка-лар янында үз-үзеңне тотарга өйрәтү, ярдәмчеллелек, пөхтәлек тәрбияләүне дәвам итү. |
| | IV | "Әнисә әбинең чынаягы" | Балаларны эче куыш форма ясау өчен балчык йомарламын басарга өйрәтү, әвәләү материалыннан эшләнмә ясаганда, өлешләрне кушу һәм сылау күнекмәләрен ныгыту. |
| февраль | II | «Йорт төзибез» | •Берничә кисәктән торган пред-метларны кисеп ябыштыруда берләштерергә өйрәтү. Геометрик фигураларны аерырга өйрәтүне дәвам итү (өчпочмак, түгәрәк, шакмак)Төсләр белемен ныгыту.Балаларның конструктив күзаллауларын үстерү. |
| | IV | «Безнен урам йортлары» | •Тәрбияче тарафыннан хәзерләнгән төрле формадагы, зурлыктагы һәм төрле төстәге кисәкләрне кәгазьгә алдан та-ратып салырга һәм билгеле бер тәртиптә тезү күнекмәсен үстерү.Пөхтә эш күнекмәләрен форма-лаштыру.Туган шәһәргә мәхәббәт хисе тәрбияләү. |
| март | II | «Әниемә бүләккә умырзая чәчәге» | •Балаларны берничә кисәктән торган сурәт төзергә өйрәтү.Балаларда матур бүләк ясарга омтылыш уяту.Эстетик караш тәрбияләү, об-разлы күзаллаулар тудыру. |
| | IV | «Нурлы кояш» | • Кисеп ябыштыруда кояш образы тудыру. Кәгезь биттәндә предметларны дөрес урнаштыру, төслерләрне белүләрен ныгыту. Балаларда күмәк эшнең нәтиҗәсен күрүдән шатлану хисләре уяту.Әрмән халык җыры «Кояш кайда йоклы?» белән таныштыру. |
| апре ль | II | «Машина» | •Композиция хисен үстерү.Әзер формаларны билгеле бер тәртиптә ябыштырырга өйрәтүне дәвам итү.Пөхтә эш күнекмәләрен форма-лаштыру. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | IV | «Паровоз» | •Берничә кисәктән торган пред-мет ясарга өйрәтүне дәвам итү.Балалргa үзләре теләгән төрле төстәге кисәкләрне кәгазьгә та-ратып салырга һәм билгеле бер тәртиптә тезеп ябыштырырга өйрәтүне дәвам итү.Кисеп ябыштыруны чиратлаш-тыру. (Вагондагы кешеләрне ясау) |
| май | II | «Тиздән җәй җитә» | •Әзер фигуралардан, компози-ция төзергә өйрәтү. Мөстәкыйль рәвештә күбәләкләргә, чәчәкләргә урын табып урнаштыру.Рәсемне биттә матур итеп ур-наштырырга өйрәтүне дәвам итү.Балаларны эстетик яктан тәрбияләү: туган якның табигать матурлыгына уңай эмоциональ караш тәрбияләү. |
| | IV | «Үләндә кем яши» | •Тәрбияче тарафыннан хәзерләнгән төрле формадагы, зур-лыктагы предметлардан, аерым бер композиция төзергә өйрәтү.Төс исемнәрен (кызыл, сары, зәңгәр, яшел, алсу, сыек зәңгәр) ныгыту.Балаларда табигатькә карата сакчыл караш тәрбияләүне дәвам итү. |

***Әвәләү.***

Әвәләп ясау белән кызыксынуны үстерү; балчыктан (тозлы камыр, пластилин) әвәләү күнекмәсен камилләштерү.

Зур кисәктән кечерәк кисәкләр өзеп яки чеметеп алу, аларны бармаклар ярдәмендә түгәрәкләп тәгәрәтү, өлешләрне тоташтыру (чәчәк, гранат, миләш җимешләре); янчелгән шарның өстен шомарту, җиңел генә тарттырып, кырыйларын чеметкәләп чыгу - бөрү (гөбәдия, вак бәлеш һ. б.) күнекмәләре формалаштыру. Махсус таякчык (стека) ярдәмендә ике яки дүрт кисәккә бүлеп (бәлеш кисәкләре), килеп чыккан формаларны үзгәртергә тырышуларын хуплау.

Яңа форма барлыкка китерү өчен, шарның уртасын яньчеп, чокыр ясау ысулын куллану. Махсус таякчыкны файдалану ысуллары белән таныштыру. Әвәләп ясалган әйберләргә шушы таякчык ярдәмендә милли бизәкләр төшерергә омтылуларын хуплау.

Балчык (тозлы камыр, пластилин) белән пөхтә итеп эшләргә күнектерү.

Әвәләп ясалган әйберләрне күмәк композициягә (тәлинкәдәге сый, чәй сервизы һ. б.) берләштерү. Уртак эш нәтиҗәсен күреп шатлану хисләре уяту. Декоратив әвәләп ясауда халык уенчыклары үрнәкләре (Шәмәрдән, Актүбә һ. б. уенчыклар) буенча иң гади образлар тудырырга теләк уяту.

Өстәл театрында куллану өчен, татар халык әкиятләре буенча сюжет әвәләп ясауга кызыксыну һәм теләк тудыру. Балаларда өлкәннәр белән уртак эш нәтиҗәләрен күреп шатлану хисләре уяту.

***Комплекслы – тематик план***

| ай | атна | Эшчәнлек темасы | Бурычлар |
| --- | --- | --- | --- |
| сентябрь | I | «Әвәләргә өйрәнәбез» | •Балчыкның үзлекләре белән (йомшак, кисәкләргә аерырга, әвәләргә мөмкин) таныштыруны дәвам итү.Балаларда әвәләү шөгыленә кызыксыну тәрбияләү. Балаларны пөхтә, матур эшләргә өйрәтү. |
| | II | «Аюга күчтәнәч» | •Балаларны балчык йомарла-мыннан кечерәк кисәкне аерып алырга, балчыкны кул белән ту-рыга тәгәрәтеп әвәләргә өйрәтүне дәвам итү.Балаларда сюжетлы уеннар уйнау теләген булдыру.Балаларда бер-берсенә ярдәм итү теләген үстерү.<br>Балаларны Р. Харисның «Лап-лап» дигән шигыре белән таныштыру |
| | III | Әвәләү «Клиндер» | •Балчыкны турыга әвәләгәндә барлыкка килгән форманы бөҗра ясап тоташтыру.Балаларда уйнау теләген үстерү.Балаларда төрле халык мәдәниятына, сәнгатенә соклану хисе тәрбияләү.<br>Рус халык шигырьләрен уку. |
| октябрь | I | «Алмалар һәм җиләкләр» | •Балчыкны кул белән түгәрәкләп тәгәрәтергә өйрәтүне дәвам итү.•Балаларны балчык йомарла-мыннан кечерәк кисәкне аерып<br>алунуы ныгыту.Балаларда туган якка,үсемлекләр дөньясына карата мәхәббәт хисе тәрбияләү. |
| | II | «Тиен очен чикләук» | •Балаларны төрле зурлыктагы түгәрәк формаларны әвәләргә өйрәтүне дәвам итү.<br>•Балаларның уйнау теләген арттыру. Балаларда туган як табигатенә сакчыл караш уяту.<br>•Хайваннарга карата сакчыл караш тәрбияләү. |
| ноябрь | I | «Әниемә кучтәнәч» | Бармак белән эшләп, тирәнәй-түче рельеф кулланып эшләнмәне бизәргә өйрәтү.<br>Балчыкны кул белән тәгәрәтеп әвәләү, шарны басып изү.Балчык белән пөхтә эш итү кү-некмәләрен ныгыту.Әвәләү күнекмәләрен ныгыту әти-әниләргә карата ихтирам хисе тәрбияләү.Татар шагыйре Газиз Набиуллин-ның «Әниемә булышам» шигыре белән таныштыру. |
| | II | «Очкычлар аэродромда» | •Балаларны ике кисәктән торган катлаулы булмаган предметлар әвәләргә өйрәтү,<br>•Әвәләү ысулларын ныгыту.Мускулларның киеренкелеген арттыру. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| декабрь | I | «Кар бабай» | •Әвәләү эшчэнлегендә кызыксыну тудыру.Балаларны балчык йомарламыннан кечерәк кисәкләрне аерып алырга, балчыкны кул белән турыга тәгәрәтеп әвәләүне ныгыту. Балаларда эшнең нәтиҗәсен күрүдән шатлану хисләре уяту. |
| | II | «Аумас  курчак» | •Балаларны бер формадан торган, әмма төрле зурлыктагы бер-берсенә тыгыз тоташтырып уенчык әвәләргә өйрәтү.Үз эшеңне уйлап башкарырга өй-рәтү. Балаларда төс һәм форма хисе үстерүне дәвам итү.Пөхтәлек, мөстәкыльлек булдыру. |
| январь | I | «Теләгән уен-чыкны әвәләү» | •Балаларны үз теләкләре буенча уенчык әвәләргә өйрәтү, аның төп өлешләрен күрсәтергә өйрәтүне дәвам итү.Әвәләү ысуларын ныгыту. Үзләренең эшләренә нәтиҗә ясарга өйрәтү. Эш барышында балаларда сабырлык, пөхтәлек хисен тәрбияләү. |
| | III | «Куян — озын колак, кысык куз, кыска койрык» | •Әвәләү ысуларын ныгыту. 2-3 кисәктән торган предметларны, бер-берсенә кысып ябыштыру юлы белән әвәләргә өйрәтү. Башын һәм гәүдәне тәгәрәтеп, кылакларын турыга әвәләргә өйрәтү.Берничә өлештән торган гадирәк предметларны тоташтырыга өйрәтү.<br>•Балаларда мөстәкыйльлек, ак-тивлык, иҗат тәрбияләү, шатлык хисләр уяту, сөйлем телен үстерү. |
| февраль | I | «Куянны сыйлыйбыз» | •Балаларны үзләре ниятләгәнчә әвәләргә өйрәтү.Кирәкле кулланмаларны сайлап алуны ныгыту, әвәләүне ахырына кадәр җиткерү.<br>Балаларда хайваннарга кара-та, ярдәмчелек, мәхәббәт хисләре уяту. |
| | III | «Зур һәм   кечкенә очкычлар» | •Биремгә карап төзүне үзгәртергә өйрәтү.Һава транспорты әвәләргә өйрә-түне ныгыту(очкыч).Әвәләү ысуллары турындагы күзаллауларын ныгыту.<br>Эшнең нәтиҗәсен күрүдән шат-лану хисләре уяту. |
| март | I | «Әниемә күчтәнәч» | •Түгәрәк формадагы күчтәнәчләр әвәләргә өйрәтү, ал арны дөрес итеп терле үрнәкләр бәлән бизәргә өйрәтүне дәвам итү. Балаларның активлыгын һәм иҗат иркенлеген арттыру.Әниләренә карата хөрмәт хисе тәрбияләү.Н.В. Беловның «Пирог» шигыре белән таныштыру. |
| | III | «Чеби» | • Балаларда кечкенә чебиләр әвәләргә кызыксыну уяту. Берничә кисәктән торган пред-метларны әвәләргү өйрәтүне дәвам итү. • Чеметеп ябыштыру алымын ныгыту.<br>• Балаларда төс, форма хисен үстерү. Балаларда шатлык хисе уяту. |
| апр ель | I | «Озын елан» | •Балаларны чиратлаштырып (Төс, форма яки зурлык буйлап)төрледән-төрле бизәкләр ясарга өйрәтү.[ш] хәрефен дөрес әйтергә өйрәтүне ныгыту. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | •Әвәләү эшчәнлегенлә кызыксы-ну тудыру. Н.В. Белованың «Змея» шигыре белән таныштыру |
| | III | «Кошлар» | •Балаларга өйләнә- тирәдәге предметларның һәм табигатьнең матурлыгын сурәтләп бирергә тәкъдим итү, түгәрәк һәм озынча формаларны әвәләргә өйрәтүне дәвам итү.<br>•Әвәләгән предметларны әвәләү тактасына куеп, аларны хәрәкәтләндерү (басып тора, җим ашый).Кошларга карата сакчыл караш тәрбияләү. |
| май | I | «Корт» («Гусеница») | •Балаларны ике өлештән тор-ган төрле предметлар әвәүләргә өйрәтүне дәвам итү. Предметлар-ны куплек санда ээйтергә өйрәтү.Табигатьтә бөҗәкләрне күзәтергә кызыксыну үстерү.Балаларда иҗади күзаллаулар булдыру. |
| | III | «Кырыгаяк» | • Балаларны төрле бөҗәк образ-лары әвәләргә өйрәтүне дәвам итү. • Белгән әвәләү ысулларын фай-даланырга өйрәтү • Балаларны иҗади күзал-лауларын үстерүне дәвам иту.Табигатькә сакчыл караш тәрбияләү. |